وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№6 (227). Июнь / Шәгъбан – 1435

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ




2 бит

## Татарстан мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИНның рамазан ае башлану унаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ




8-9 бит

## Аллаһка шөкер итү, бабаларыбыз рухына дога кылу өчен ЯНӘ БОЛГАРГА ҖЫЕЛДЫК



13 бит

## БАЛАЛАРЫБЫЗ МӨСЕЛМАН ҖӘЙЛӘҮЛӘРЕНДӘ ЯЛ ИТӘ



6 бит

## КАЙСЫ МӘЧЕТЛӘРДӘ ИФТАР АШЛАРЫ УЗДЫРЫЛА

# Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның рамазан ае башлану уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

**Әссәләәму галәйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәәтүһ!**
**Мөхтәрәм дин кардәшләребез!**

Сезне Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән Изге рамазан ае башлану белән чын күңелдән тәбрик итәм!

Мөбарәк рамазан ае - барлык гөнаһлардан арыну, рухи яктан пакьләнү, миһербанлылык, шәфкатьлелек һәм юмартлык ае.

Коръәндә әйтелгән: "Ий, иман китергән бәндәләр, сездән алда килеп-киткәннәргә фарыз ителгән кебек, ураза тоту сезгә дә фарыз кылынды. Бәлки сез бу фарызларны үтәп шаять тәкъва булырсыз" ("Бәкара" сүрәсе, 183 нче аять).

Ураза тоту безнең өчен рухыбызны чистарта торган бер сынау. Рамазанда Аллаһы Тәгалә кушканнарны үтәп, Раббыбыз ризалыгын, әҗер-саваплар алырга, җәннәткә якынаерга күп мөмкинлекләр туа. Бу айда Аллаһы Тәгалә Үзенең рәхмәт ишекләрен ача, игелекле гамәлләребез өчен савапларны күпкә арттырып бирә. Гомеребез бик кыска, шушы гомеребездә насыйп булган бернинди байлыкны да бу мөмкинлекләр белән чагыштырып булмый. Рамазан ул безгә Аллаһы Тәгаләнең бер зур бүләге.

"Рамазан ае кешеләргә тугры юл күрсәтүче, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр. Шуңа күрә шушы айга килеп ирешкәннәр ураза тотсын. Хаста булганнар яки сәфәрдәгеләр (тотылмаган көннәрне хисабынча) башка көннәрне ураза тотар. Аллаһ сезгә җиңеллек тели, кыенлык теләми. Санаулы (ураза) көннәрен тәмам итеп, сезгә тугры юл күрсәткәне өчен, Аллаһны олылагыз, бәлки сез шөкер итәрсез?" ("Бәкара" сүрәсе, 185 нче аять).

Рамазан ае дәвамында изге гамәлләребез, мәрхәмәтле эшләребез һәм догаларыбыз белән Аллаһы Тәгаләнең чиксез рәхмәтенә, дөнья-ахирәт бәхетсәгадәтенә ирешергә тырышыйк. Кемнәргә ярдәм итә аласыз - шуларга ярдәм итегез, кемнәрне хәтерлисез - дога кылыгыз. Мохтаҗларның, ятимнәрнең күңелләрен шатландырыйк, туган-тумача, кардәшләребезнең хәлләрен белик, шул вакытта, иншә Аллаһ, гыйбадәтләребез, гамәлләребез кабул булыр.

Аллаһ Раббыбыз рамазан айларында мәрхәмәтле эшләрдә берләшергә насыйп итсә иде, ил-көннәребезгә тынычлык, иминлек һәм саулык-сәламәтлек бирсә иде. Амин.

# ҖӘМӘГАТЬКӘ ТУПЛАНГАН МӨСЕЛМАН АДАШМАС

**Казанда "Милли тормыш һәм дин" дип аталган V Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы булды. Анда Россия Федерациясенең 52 төбәгеннән 815 кеше катнашты. Форум эше "Татар гаиләсен саклауда дини йолаларның һәм милли гореф-гадәтләрнең тоткан урыны һәм роле", "Исламда социаль хезмәт", "Дөньяви җәмгыятьтә имамның тоткан роле һәм урыны" дигән темалар буенча өч секциядә алып барылды. Аларда татар мөселман гаиләсе каршында торган кискен проблемалар тәгаенләнде, имамнар көндәлек эшләрендә файдаланырлык фикер-тәкъдимнәр әйтелде.**



Форумда Координацион совет оештыру тәкъдиме дә хупланды. Ул Россия Федерациясендә әйдәп баручы дини үзәк, форумнар арасында даими эшли торган эшче орган буларак кузаллана. Кулга-кул тотынышып, даими эшләп кенә хәл итәрдәй проблемалар Россия төбәкләрендә дә, Татарстанның үзендә дә бар. Форум мәгълүматларына караганда, Россия төбәкләренең кайберләрендә 5әр мөфтият барлыкка килгән, тегe яки бу мәсьәләдә имамнарның һәркайсы үзенчә җавап бирә икән һ.б. Татарстанда бүгенге көндә 1,5 мең мәчет бар, дип горурлансак та, аларның 80гә якыны ачылмый, кайсыларына картлар гына җомга намазларына йөри. Димәк, халык белән эшләүнең башка формаларын табу, имамнарның үрнәк шәхес итеп җитлегүенә ирешү - инде күптән өлгергән мәсьәлә.

Бу темага сөйләшүләр икенче көнне форумның пленар утырышында да дәвам итте. Утырышта ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Җөмһүрияте мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Югары мөфти, Россия мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте рәисе Тәлгать Таҗетдин, Россиянең Европа өлеше мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Равил Гайнетдин, ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Россия Дәүләт Думасы депутаты, федераль татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Илдар Гыйльметдинов, ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров һ.б. рәсми затлар катнашты.

Форум Казан казые, Шамил мәчете имам-хатыйбы Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдиновның Коръән сүрәләре укуы белән башланып китте. ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов бисмилла белән сүзен башлап, бирегә килүләре өчен делегатларга рәхмәт белдерде. "Форум һәм аның кысаларында Изге Болгар җиренә барып дога кылу, очрашып сөйләшү-киңәшләшү матур традициягә әйләнде, - дип билгеләп үтте Президент. - Форумның Координацион советы төзелеп, килешенгән мәсьәләләрне хәл итү өстендә даими эшли башлаячак. Безнең бергә булуыбыз үз халкыбыз, үз динебез өчен кирәк, бергә булсак кына зур эшләр башкара алырбыз. Татарстаннан читтәге татар халкы, аның теле, мәдәнияте, гореф-гадәтләре сакланышында сезгә таянабыз. Безнең өчен боларны беркем башкарачак түгел", - дип Президент дин әһелләренә рәхмәт белдерде.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үз чыгышын узган ел кабул ителгән "Ислам һәм татар дөньясы: үсешнең концептуаль нигезләре" дип аталган документны искә төшерүдән башлады. "Анда татарларның ислам тарихы, шәригать юнәлеше, өммәтебез язмышына бәйле мәсьәләләр билгеле бер тәртипкә салынган. Төрле өлкәләргә кагылышлы сорауларга аңлатма бирелгән. Бу концепция юлчы кулындагы картаны хәтерләтә. Ул картасына карый да үзенә кирәк юнәлешне таба. Кирәк икән, тарихи урынга бара, кирәк икән мәчетне табып гыйбадәтен кыла. Концепция бүгенге көн татар мөселманнары өчен менә шундый бер карта ролен үти. Концепцияне укып татар мөселманнарының юл башын күрергә һәм алга таба аның кайсы тарафка алып барганын чамаларга була.

Ләкин шуны аңларга кирәк: карта юлны табарга булыша, ә концепция юлны гына күрсәтми, шушы юлдан барганда нинди гамәлләр кылуны да күздә тота. Гамәлсез аның файдасы бик аз булыр. Гамәлсез юл - бушка үтелгән юл, бушка сарыф ителгән вакыт бит ул. Безнең бүген бирегә җыелу һәм фикер алышу шул гамәлләрнең берсе. Йөзләгән татар имамнары, зыялылар, рәсми вәкилләр җәмәгать булып тупландык. Бер-беребезгә изге теләкләр әйтәбез, ниятләр белән уртаклашабыз. Пәйгамбәребез (с.г.в.) үзенең бер хәдисендә: "Аллаһы Тәгалә җәмәгатькә тупланган мөселманнарны адаштырмас, Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгалә җәмәгать белән бергә булганнарга якын тора", - ди.

Җыен, гомумән, гамәлләрне барлый торган чара да булырга тиеш, - дип мөфти хәзрәт соңгы елда Татарстан мөселманнары кылган кайбер гамәлләрне дә искә төшереп үтте. - Концепциядә язылганнарны күздә тотып, республикада 2014 елны "Гореф-гадәтләрне торгызу елы" дип игълан иттек. Безнең халык юкка гына, илен белмәгән - игелексез, халкын белмәгән - холыксыз, нәселен белмәгән - нәсәпсез, дип әйтми. Татар халкының рухи мирасын өйрәнү - исламга дәгъвәтнең нәтиҗәле юлы ул. Икенчедән, мәдрәсәләргә бабаларыбыз укыган дәреслекләрне кире кайтару ниятенә алындык. Мәрҗани, Курсавиның гарәпчә язылган китапларын бастырдык, Ялчыголны татарча чыгардык. Татар имамнарының вазыйфаларын, дәрәҗәләрен гыйлем саклый. Безнең бабалар зур галим имамнар булган. Хәтта башка илләрдәге мөселманнарга гарәп телендә ислам өйрәткәннәр. Алга таба республикада дини гыйлем ияләре тагын да күбрәк булсын.

Тагын бер проектка тукталып үтәсем килә. Узган ел сыйфатлы дини китапларга ихтыяҗ артуны исәпкә алып, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан "Хузур" нәшрият йорты оештырылды. Ул 27 китап бастырып чыгарды (гомуми тираж 136 мең данә).

Моннан тыш Татарстан имамнары өчен кварталга бер тапкыр татар телендә "Шура" журналы чыга. Анда җомга вәгазьләре, дини сорауларга җаваплар, мәкаләләр, хәзрәтләрнең язмалары, тарихи очерклар, иске татар телендәге текстлар бастырыла. Шулай ук 13 мең тираж белән "Дин вә мәгыйшәт", "Умма" газеталары дөнья күрә, дистәләгән сайтлар эшли. Раббыбыз бу эшләрне дәвамлы һәм бәрәкәтле итсә иде.

(Ахыры 8 нче биттә)

# РАМАЗАН АЕНЫҢ БАШЫН ҺӘМ АХЫРЫН БИЛГЕЛӘҮ

**Айның һәр төнне яңа урында, шулай ук бер урында башка урынга караганда иртәрәк яки соңрак калкуын күзәтеп булганга, галимнәр арасында бу турыда бернинди каршылыклар тумый. Ләкин ай башын һәм ахырын билгеләүдә һәм моның дини кануннарны чыгаруга тәэсир итү-итмәве мәсьәләсендә бәхәсләр туа, чөнки күк йөзендә ай төрле урыннарда һәм төрле вакытта калка.**



Мәсәлән, бер мөселман илендә яңа туган айны күрсәләр, башка илләр дә аны күргән дип исәпләнәме, әллә юкмы? Һичшиксез, кояшның төрле урыннарда һәм төрле вакытта чыгуы игътибарга алына. Шуңа күрә бер илдә намаз башка илгә караганда иртәрәк яки соңрак укыла. Яңа туган айга килгәндә бу ничек карала соң? Айның төрле урыннарда төрле вакытта калкуын игътибарга алырга кирәкме? Кояш чыгу вакытын игътибарга алуның сәбәбе булып, кояш чыгу һәм батуга бәйле намаз һәм ураза кебек гыйбадәт кылуларның башын һәм ахырын билгеләү тора. Рамазан аеның башлануы яңа туган айны күзәтүгә бәйле булуда бердәм фикер бар.

Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә болай ди: "Сездән рамазан аена ирешкән һәрберегез, әлбәттә, ураза тотсын!" ("Бәкара" сүрәсе, 185 нче аять).

Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) болай дип әйтүе җиткерелә: "Яңа туган айны күргәч, ураза тотыгыз, яңадан яңа туган айны күргәч, авыз ачыгыз (бәйрәм итегез)".

**Бу сорауда каршылыклар ике яклы:**

1. Рамазан аеның башлануын без техник чаралар кулланып билгели алабызмы?

2. Әгәр дә рамазан аеның башлануын техник чаралар кулланып яки үз күзебез белән күреп билгеләсәк, бу башкалар өчен дә мәҗбүри буламы? Ягъни төрле җирлектә төрле вакытта яңа туган айның калкуын игътибарга алырга кирәкме, әллә юкмы? Әллә моны бер илдә яшәүчеләр генә игътибарга алырга, ә башкалар көтәргә тиешме?

Техник чаралар аша алынган мәгълүматларга таянып, без рамазан ае уразасын тота башлый алабызмы?

Әбү Хәнифә мәзһәбендә, аяз көнне рамазан ае башланганын билгеләү өчен бер диндар яки халәте билгеле булмаган кешенең яңа туган айны күрүе турында күрсәтүе җитә. Китапларда "мастуруль-хәл" (билгесез) термины шәхесе билгеле булган, ә халәте билгеле булмаган кешене аңлата. Шәфигый һәм Хәнбәли мәзһәбләрендә бер диндар кешенең күрсәтүе җитә. Малики мәзһәбендә ике диндар кешенең күрсәтүе кирәк. Үткән заман факиһларында (шәригать кануннарын яхшы белүчеләрдә) бүгенге көн технологияләре булса, алар шулай ук бер кеше күрсәтүе белән генә канәгать булырлар идеме? Әлбәттә, алар заманча технологияләр белән расланган "хабару-вахид"ны да игътибарга алган булырлар иде, яисә техник чаралар күрсәтүе белән генә канәгать булырлар иде. Бу сорауда бер яки ике кеше күрсәтүе, төгәл мәгълүмат алу өчен түгел, ә чамалау өчен кирәк. Хата җибәрмәгән техник чаралар күрсәтүләрен куллану саклык принцибына билгесез бер кеше күрсәтүенә караганда күбрәк туры килә. Фикъһ китапларында язылган "айның башы һәм ахыры исәп-хисапка нигезләнеп билгеләнгән очраклар исәпкә алынырга тиеш түгел" сүзләре, минемчә, ул заманда бу исәп-хисап белән мөселманнар түгел, ә ышаныч белдермәгән фасикълар (әхлак ягыннан бозык кешеләр) шөгыльләнүенә нигезләнә. Бүгенге көндә исә исәп-хисапны мөселманнар ясый. Аллаһы Тәгалә Илчесенең (с.г.в.) бу сорауны күрүгә бәйләвенә килгәндә, моны күз белән карап күрү дип кенә түгел, ә киң мәгънәдә аңларга кирәк. Бу очракта телескоп яки башка техник чараларны куллану да җитә. Астрономик исәп-хисапларны игътибарга алмау һәм яңа туган айны күз белән күрүне шарт итеп кую, Аллаһы Тәгалә Илчесе (с.г.в.) заманнарында хаҗга җәяү яки дөяләргә атланып барганнар, транспорт чараларын кулланырга ярамый дип аларга кулланырга, баш тартуга тиң.

"Ихтиляфуль-маталиг"ны игътибарга алырга кирәкме?

"Ихтиляфуль-маталиг" - яңа туган айның төрле урыннарда төрле вакытта калкуы. Мәзһәбләр арасында бу сорауда каршылыклар бар. Әлбәттә, төрле фикерләр арасыннан мөселманнарга туры килгәнен сайларга кирәк. Мәзһәбләргә килгәндә исә:

Әбү Хәнифә мәзһәбе фикере буенча, яңа туган айның төрле урыннарда һәм төрле вакытта калкуы игътибарга алынырга тиеш түгел. Ягъни, көнчыгышта яшәүче кешеләр яңа туган айны күрсәләр, көнбатышта яшәүчеләр дә уразага керергә тиешләр.

Малики мәзһәбендә бу мәсьәләдә өч фикер бар:

1. "Ихтиляфуль-маталиг" бер очракта да катгый рәвештә игътибарга алынмый. Шуңа күрә Әбү Хәнифә мәзһәбендәге кебек үк, яңа ай тууы турында ишеткән һәр мөкәлләф ураза тота башларга тиеш.

2. Әгәр дә яңа туган айны шул җирлектә билгеләгән хаким күрсә, "ихтиляфуль-маталиг" игътибарга алынмый һәм шул җирлектә яшәүчеләр уразага керәләр, ә башка җирлектә яшәүчеләр шәгъбан аеның 30 нчы көнен тәмамлыйлар.

3. "Ихтиляфуль-маталиг" игътибарга алына. Ә яңа туган айны күргән илдән еракта яшәүчеләр шәгъбан аеның 30 нчы көнен тәмамлыйлар.

Шәфигый мәзһәбендә шулай ук бу мәсьәләдә төрле фикерләр бар. Имам Нәвави болай ди: "Яңа туган ай күренгән җирлеккә якын җирләр, шул җирлеккә тиң. Димәк, алар өчен ураза тота башлау ваҗиб. Ышанычлы фикер буенча, еракта урнашкан җирләрдә яшәүчеләр өчен бу ваҗиб түгел". Ягъни алар шәгъбан аеның 30 нчы көнен тәмамлыйлар. Бу "ихтиляфуль-маталиг"ның игътибарга алынуын күрсәтә.

Хәнбәли мәзһәбе: Ибн Кудама үзенең "Әл-Мугни" китабында, бер җирдә яңа туган ай күренсә, бу башкалар өчен дә мәҗбүри булып тора, ди.

Күрүебезчә, мәзһәбләрдә "ихтиляфуль-маталиг" игътибарга алынырга тиеш түгел дигән фикер әһәмиятлерәк булып санала. Бу фикер барлык мөселманнарны берләштерү максатыннан чыгып караганда да кулайрак.

Күз белән күрү һәм астрономик исәп-хисаплар бер-берсенә каршы килсәләр, нишләргә?

Һичшиксез, иң яхшысы - астрономик исәп-хисапка туры килгән күз белән күрү. Ләкин, кызганыч, бу күп очракта мөмкин түгел. Ясалган нәтиҗәләр календарьда күрсәтелгәннәргә туры килми. Бу очракта нәрсә эшләргә соң? Әйткәнемчә, астрономик исәп-хисаплар күрүнең бер төренә керәләр, һәм хәдистә билгеләнгән "күрү" боерыгы бу исәп-хисапларны да үз эченә ала. Шулай итеп, яңа туган айны күрү турындагы ике хәбәр арасында каршылык туа. Әлбәттә, бу очракта саклык принцибына нигезләнеп эш итү кирәк. Мәсәлән, күз белән күрү шәгъбан аеның 29 нчы көне уразаның беренче көне икәнен күрсәтсә, ә астрономик исәп-ләүләр уразаның 30 нчы көндә башлануын күрсәтсәләр, һәм киресенчә булган очракта, безнеңчә, уразага 29 нчы көнне керергә кирәк. Бу очракта уразаны "йаумушак" (шикле көндә) тотабыз дип исәпләнәчәкме? Без бу турыда яңа айны күрү турындагы сүзнең көчсез булмавыннан чыгып әйтәбез. Киресенчә булган очракта, астрономик исәпләүләргә нигезләнергә кирәк.

Аллаһы Тәгаләгә яхшырак билгеле!

***Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН, Татарстан Республикасы мөфтие***

# НАМАЗ УКЫМАГАН КЕШЕНЕҢ УРАЗАСЫ КАБУЛ БУЛАМЫ?

**Сорауга Татарстан Республикасының көнчыгыш төбәге казые, Әлмәт районы имам-мөхтәсибе һәм шәһәрнең җамигъ мәчете имам-хатыйбы Фәһим хәзрәт ӘХМӘТҖАНОВ җавап бирә.**

Дөрестән дә, намаз уку ул - динебезнең асыл нигезен тәшкил итүче гыйбадәт. Әмма шәригатебездә һәрбер гыйбадәт аерым-аерым карала. Ягъни һәрбер гыйбадәткә үзенә аерым бербөтен итеп игътибар бирелә. Әлбәттә, намаз турында: "Әгәр намазы булмаса, башка гыйбадәтләре дә кабул булмый", - дигән хәдисләр бар, ләкин ул хәдисләр, адәм балалары намазга җиңел карамасын өчен, намазның никадәр өстен гыйбадәт икәнлеген раслый торган мәгънәдә килә. Безнең соравыбызга килгәндә исә, димәк ки, намаз аерым бер төр гыйбадәт, ураза тоту - аерым бер төр гыйбадәт, хаҗ кылу да, зәкят бирү дә - шулай ук. Әйтергә кирәк, шулай булгач, фикъһ галимнәре: "Кеше намаз укымый икән әле, ләкин ул ураза тота, бу - һичшиксез күркәм гамәл", - ди. Һичкем болай дип әйтә алмый (аңарга туры дәлил юк): "Намаз укымасаң, синең уразаң кабул булмый".

Нәтиҗә буларак, кешегә: "Намаз укымасаң, ураза тотма, ул кабул булмый яисә син буш гамәл кыласың", - дип әйтү дөрес түгел. Болай дип әйтүдән саклансак, ул кешенең күңеле йомшарачак, калебе пакьләнәчәк һәм дингә, намазга ул тизрәк якынаячак, көннәрдән бер көнне намазга басып китәр. Әһле сөннәт галимнәренең юлы бу мәсьәлә буенча түбәндәгечә: әгәр ул кеше барлык уразаларын да тота, әмма намазларын үтәмәсә, аның өстеннән ураза бурычы төшәчәк, әмма укылмаган намазлары өчен җавапка тартылачак. Киресенчә булган очрактагы кебек: ягъни, намазлары тәртиптә булып, уразасында кимчелек булса, уразасы өчен җавап тотар. Башка гыйбадәтләре белән дә шулай ук. Моңа дәлил таләп итүчеләргә җавап шул: Коръәндә ("Зәлзиләт (Җир селкенмәк)" сүрәсе, 7-8 нче аятьләр) болай диелә:

فَمَن يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ خَيْرًا يَرَهُ

وَمَن يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ شَرًّا يَرَهُ

**"7. Берәү тузан бөртеге хәтле генә яхшылык кылган булса, аның җәзасын (савабын) күрер.**

**8. Вә берәү тузан бөртеге хәтле гөнаһ эшләсә, аның җәзасын күрер".**

Ә бу бит инде (сүз ураза турында бара) тузан бөртеге кадәр генә изгелек түгел, аңардан бик күпкә өстенрәк гыйбадәт.

# УРАЗАНЫҢ ФАЗЫЙЛӘТЛӘРЕ ТУРЫНДАГЫ ХӘДИСЛӘР ҺӘМ РИВАЯТЬЛӘР

**Әбү Һүрайра (радыйаллаһу ганһү) тапшырган риваятьтә Рәсүлуллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм әйткән): "Аллаһ: "Адәм углының эшләгән һәр хәерле эше үзе өчен, әмма ураза алай түгел. Ураза бары тик минем өчен генә. Аның савабын да мин бирермен", - дип әмер итте.**

**Ураза - ул калкан. Һәркайсыгыз ураза toткан көнне яман сүз сөйләшмәсен һәм яман гамәл кылмасын, дошманлык (яки тавыш-гауга) куптармасын.**

**Әгәр берәү уразалы кешене сүкмәкче яки кыйнамакчы булса, аңа шундук: "Мин ураза тотам", - дип әйтергә кирәк.**

**Мөхәммәднең нәфесенә (җанына) хуҗа булган Аллаһка ант итәм: ураза тотучы кешенең авызыннан килүче ис Аллаһ алдында мускус исеннән дә хушрак һәм чистарак.**

**Ураза тотучыны сөендереп кәефен күтәрәчәк ике нәрсә бар. Берсе** - (ифтар вакытында) **ураза бозылганда сөенү, икенчесе - Раббысына кавышкан вакытта ураза**(ның савабы) **белән сөенү"** (Бохари, "Саум", 9, 2/228; Мөслим, "Сыйам", 164; Әбү Дауд, "Саум", 25; Тирмизи, "Саум", 55; Нәсаи, "Сыйам", 41; Ибн Мәҗа, "Сыйам", 1; Мүвәттаг, "Сыйам", 58).

Сәхл (радыйаллаһу ганһү) тапшырган бер риваятьтә Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм) болай дигән: **"Җәннәттә әр-Рәййан дигән бер ишек бар. Бу ишектән Кыямәт көнендә бары тик ураза тотучылар гына керәчәк. Аннан ураза тотучылардан башка берәү дә керә алмаячак.**

(Кыямәт көнендә): "Ураза тотканнар кайда?" - дип сораячаклар. **Ураза тоткан кешеләр торып, шул ишектән кереп китәчәкләр.**

**Алар кереп беткәч, ишек ябылачак һәм моннан соң ул ишектән башка берәү дә керә алмаячак"** (Бохари, "Саум", 4, 2/226; Мөслим, "Сыйам", 166; Тирмизи, "Саум", 55; Нәсаи, "Сыйам", 43).

Әбү Һүрайрадан (радыйаллаһу ганһү) риваять ителгәнчә, Рәсүлуллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм) әйткән: **"Аллаһ юлында пар** (алтын белән көмештән) **сәдака биргән кешеләрне җәннәт капкаларыннан: "Әй, Аллаһның коллары!** (Бирегә килегез!) **Бу хәерле капка!" - дип чакырачаклар.**

**Күп намаз укучыларны** (җәннәтнең) **намаз капкасыннан чакырачаклар. Җиһад кылучыларны җиһад капкасыннан чакырачаклар.**

**Ураза тоткан кешеләр әр-Рәййан капкасыннан чакырылачаклар. Сәдака биргән кешеләр сәдака бирүчеләр капкасыннан керәчәк".**

Моңа каршы Әбү Бәкер (радыйаллаһу ганһү): **"Атам-анам сиңа фида булсын, әй, Рәсүлуллаһ! Бу капкалардан чакырылган кешеләргә берәр зарар кылыначакмы? Бер кеше бу капкаларның барысыннан да чакырылырга мөмкинме?"** - дип сораган.

Рәсүлуллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм): **"Әйе! Барысыннан да чакыру булачак. Мин синең шул чакырылучы кешеләр арасында булуыңны телим"**, - дигән (Бохари, "Саум", 4, 2/227).

Әбү Һүрайра (радыйаллаһу ганһү) тапшырганча, Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм) әйткән: **"Рамазан ае уразасын ихлас күңел белән ышанып һәм савабын бары тик Аллаһтан гына өмет итеп тоткан һәркемнең кылган гөнаһлары ярлыканыр"** (Бохари, "Иман", 28, 1/15; "Ләйләтүл Кадр", 1; "Саум", 6; Мөслим, "Сыйам", 3, 20; "Мүсафирин", 175; Әбү Дауд, "Рамазан", 1; "Саум", 57; Тирмизи, "Саум", 1; "Җәннәт", 4; Нәсаи, "Сыйам", 39; Ибн Мәҗа, "Икамәт", 173; "Сыйам", 2, 33; Дарими, "Саум", 44; Әхмәд Ибн Хәнбәл, 2/232, 241, 385).

Әбү Һүрайрадан (радыйаллаһу ганһү) риваять ителгәнчә, Рәсүлуллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм) әйткән: "(Сәфәрдә булу) **сәбәбе һәм хасталыгы булмаган кеше, рамазанда бер генә көн ураза тотмаса, гомере буе ураза тоткан очракта да аны түләп бетерә алмас!"** (Әбү Дауд, "Саум", 38; Тирмизи, "Саум", 27, №728, 3/92; Ибн Мәҗа, "Сыйам", 14; Дарәкутни: 2/191; Әхмәд Ибн Хәнбәл: 2/386, 442, 470).

Сөләйм угылларыннан берсенең болай дигәне риваять ителгән: **"Рәсүлүллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм) боларны минем кулымда һәм үзенең кулында санады да: "Тәсбих (Сүбхәналлаһ)" үлчәүнең яртысы гына һәм "Әлхәмдүлилләһ" аны тулыландыра. "Тәкбир** (Аллаһу әкбәр)" **исә күк белән җир йөзе арасын тутыра. Ураза - сабырның яртысы, чисталык, пакьлек - иманның яртысы"**, - диде" (Тирмизи, "Дәгъвәт", 87, №3519, 5/536).

Абдуллаһ Ибн Амр (радыйаллаһу ганһү) Рәсүлуллаһның (саләллаһу галәйһи вәссәләм) әйткәнен тапшырган: **"Ураза белән Коръән Кыямәт көнендә колга шәфәгатьчелек итәчәкләр. Ураза: "Әй, Раббым! Мин аны көндезләрен ашау-эчүдән һәм җенси теләкләреннән тыйдым. Шуңа күрә мине аның өчен шәфәгатьче кыл"**, - диячәк. Коръән дә: **"Мин аны төннәрен йоклатмадым. Мине дә аның өчен шәфәгатьче кыл"**, - диячәк. Шулай итеп, икесе дә (әлеге колга) шәфәгать итәчәкләр" (Әхмәд Ибн Хәнбәл: 2/174).

Әнәс Ибн Мәлик (радыйаллаһу ганһү) тапшырганча, Рәсүлуллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм) бер көнне сәхабәләреннән: **"Арагыздан берегез бүген җеназада булдымы?"** - дип сораган. Хәзрәти Гомәр: **"Мин"**, - дип җавап биргән. Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм): **"Арагыздан берегез бүген берәр хастаның хәлен белдеме?"** - дип сорагач, Гомәр (радыйаллаһу ганһү): "**Мин**", - дигән. Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм): **"Кем сәдака бирде?"** - дип сораган. Гомәр тагын: "Мин", - дигән. Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм): **"Кем иртән уразага керде?"** - дип сораган. Гомәр шулай ук: **"Мин"**, - дип җавап биргәч, Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм): "(Җәннәт сиңа) **важиб булды, важиб булды"**, - дип боерган (Әхмәд Ибн Хәнбәл, "Әл-Мүснәд", 3/118).

Җәбир (радыйаллаһу ганһү) тапшырган бер хәдистә Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм) болай дигән: **"Һичшиксез, ураза колның үзе өчен җәһәннәмнән саклана торган калкан.** (Аллаһы Тәгалә): **"Ул** (ураза) **минем өчен һәм аның савабын да мин бирәчәкмен", - дип әмер итте"** (Әхмәд Ибн Хәнбәл, "Әл-Мүснәд", 3/396).

Абдуллаһ Ибн Әбү Әвфа (радыйаллаһу ганһү) риваять иткән бер хәдистә Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм): **"Ураза тоткан кешенең йокысы - гыйбадәт, эндәшмәве - тәсбих, гамәле даими, догасы кабул ителгән, ә гөнаһысы гафу ителгән булыр"**, - дигән (Али Әл-Мүттәки, "Кәнзүл Уммал", 8/443, №23562; Әбү Нуайм, "Хилйә", 5/83; Зәбиди, "Итхаф", 4/192; Иракый, "Әл-Мугъни", 1/232).

Ибн Амр (радыйаллаһу ганһү) тапшырган бер хәдистә Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм): **"Ураза тотучы кешенең ифтар вакытында тәгаен кабул ителә торган бер догасы бар"**, - дип әйткән (Али Әл-Мүттәки, "Кәнзүл Уммал", 8/448, №23592).

Галидән (радыйаллаһу ганһү) риваять ителгәнчә, бер хәдистә Рәсүлүллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм) болай дип әйткән: **"Ураза тоту сәбәпле, үзен җаны теләгән ризыклардан һәм эчемлекләрдән тыйган кешегә Аллаһы Тәгалә җәннәт җимешләрен ашатыр һәм җәннәт шәрабларын эчертер"** (Али Әл-Мүттәки, "Кәнзүл Уммал", 8/456, №23635; Суйути, "Әд-Дәррүл Мәнсур", 1/180).

Әбү Үмамә (радыйаллаһу ганһү) болай дигән: "Мин бер тапкыр Пәйгамбәребезгә (саләллаһу галәйһи вәссәләм) килеп: **"Әй, Рәсүлүллаһ! Мине җәннәткә кертәчәк берәр гамәл әмер ит миңа"**, - дидем. Ул миңа: **"Ураза тотуны дәвам ит, чөнки аңа тиң булырлык башка гамәл юк"**, - дип әйтте. Тагын бер тапкыр килеп, шул ук сорауны биргәндә: **"Ураза тотуны дәвам ит, чөнки аңа тиң булырлык башка гамәл юк"**, - дип җавап кайтарды (Али Әл-Мүттәки, "Кәнзүл Уммал", 8/583, №24275).

Әбү Һүрайра (радыйаллаһу ганһү) тапшырган бер хәдистә Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм): **"Ураза - сабырның яртысы. Һәр нәрсәнең зәкяте бар. Тәннең зәкяте - ураза"**, - дигән (Али Әл-Мүттәки, "Кәнзүл Уммал", 8/444, №23571).

Әбү Һүрайрадан (радыйаллаһу ганһү) тапшырылганча, Рәсүлүллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм) бер хәдистә: **"Өч төрле дога һичшиксез кабул ителә. Ураза тотучы кешенең догасы, юлчы догасы һәм мазлумның** (хаксызга җәберләнгән, рәнҗетелгән кешенең) **догасы"**, - дип әйткән (Бәйхаки, "Шуабүл Иман"; Али Әл-Мүттәки, "Кәнзүл Уммал", 2/99 Н, №3320; Нәбхани, "Әл-Фәтхул Кәбир", №5546, 1/517).

Әбү Мәлик әл-Әшгари риваять иткән бер хәдистә Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм) болай дигән: **"Чыннан да, җәннәттә шундый бер йорт бар: эченнән - тышы, тышыннан эче күренә. Аллаһы Тәгалә аны йомшак сөйләшкән, кешеләрне ризыкландырган, даими ураза тоткан һәм башка кешеләр йоклаганда төнлә гыйбадәт кылганнар өчен әзерләгән"** (Әхмәд Ибн Хәнбәл, Тирмизи, Ибн Хиббан, Бәйхаки, "Шуабүл Иман", Суйути, "Әд-Дәррүл Мәнсур",1/44; Нәбхани, "Әл-Фәтхул Кәбир", №4016, 1/367).

Бер хәбәрдә әйтелгән: **"Һичшиксез, җәннәтләр дүрт кешегә гашыйк. Болар: рамазан аенда ураза тоткан, Коръән укыган, телләрен** (ялган һәм шуңа охшаш яманлыклардан) **саклаган, күршеләрен ашаткан кешеләр.**

**Хакыйкатьтә, Аллаһы Тәгалә ифтар вакытында мөселман колының аяклары белән йөргән, куллары белән тоткан, күзләре белән күргән, колаклары белән тыңлаган, теле белән сөйләгән һәм йөрәге белән уйланган** (барлык гөнаһларны да) **гафу итәр"**.

Башка бер хәбәрдә болай диелгән:

**"Кыямәт көне җитеп, кабердәгеләр кубарылып чыкканнан соң, Аллаһы Тәгалә (җәннәт сакчысы) Ризванга: "Хакыйкатьтә мин ураза тоткан колларымны каберләреннән ач һәм сусаган килеш терелттем. Аларны тоткарламыйча, җәннәтләрдән җаннары теләгән нәрсәләр белән каршы ал", - дип әмер итәр. Ризван, җәннәт хезмәтчеләрен үзенә чакыртып: "Әй, Гыйльман һәм Вилдан! Нурдан табаклар ясагыз", - дияр. Шул вакытта ком бөртекләреннән, яңгыр тамчыларыннан, күктәге йолдызлар һәм агачлардагы яфраклардан ясалган исәпсез сандагы табаклар бик күп җиләк-җимешләр, ләззәтле һәм искиткеч тәмле ризыклар белән тутырылыр, татлы эчемлекләр китерелер.**

**Фәрештәләр үзләре янына килгән һәркемне** (дөньялыкта ураза тоткан кешеләрне) **ашатыр һәм эчертер. "Үткән көннәрегездә ашау-эчүдән тыелганыгыз өчен хәзер теләгән кадәр ашагыз һәм эчегез", - дип әйтерләр"** (Исмаил Хаккы Бурсәви, "Рухул Бәйан", 1/294).

## УРАЗА ТОТМАГАННАР ӨЧЕН ИРЕШКӘН КИСӘТҮЛӘР

Ибн Гомәр риваять иткән бер хәдистә Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм) болай дигән:

**"Өч нәрсәне саклаган кеше Аллаһның дусты була. Әлеге өч нәрсәне югалткан кеше исә Аллаһның чын дошманы була. (Болар): намаз, ураза һәм якынлык кылганнан соң чистарыну"** (Хәйсәми, "Мәҗмәгуз Зәваид", №127, 1/201).

Әбү Һүрайрадан (радыйаллаһу ганһү) тапшырылган бер хәдистә Рәсүлүллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм) әйткән: **"Узган рамазаннан түләнмәгән бурычы булган кешенең яңа рамазандагы уразасы кабул ителмәс.**

**Рамазан ае уразасының бурычы булган кешенең, әлеге фарыз бурычы капланмыйча, нәфел уразасы да кабул ителмәс"** (Әхмәд Ибн Хәнбәл, "Әл-Мүснәд", 2/352; Табәрани, "Әл-Әвсат", 2/99; Хәйсәми, "Мәҗмәгуз Зәваид", №5066, 4833, 3/415, 357).

Әлбәттә, каза кылынмаган уразасы булган кеше яңа рамазан аенда ураза тотмасын яки яңа рамазанда элеккеге уразасы ниятләп тотып бетерсен, дигән сүз түгел бу. Бу бары тик яңа тотылган уразаның кабул ителергә лаеклы камил ураза булмавын гына искәртү.

Әбү Үмамә әл-Бахили (радыйаллаһу ганһү) риваять иткән бер хәдистә Рәсүлуллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм) болай дигән: **"Берсендә мин йоклап ятканда, яныма ике кеше килде һәм, кулларымнан тотып, мине текә тауга илттеләр дә: "Мен!" - диделәр. Мин: "Моңа көчем җитмәс", - дигәч: "Без сиңа ярдәм итәрбез", - диделәр. Мин тауга менә башладым. Тигезрәк бер урынга менеп җиткәч, көчле тавышлар ишеттем һәм: "Бу нинди тавышлар?" - дип сорадым. Алар: "Бу җәһәннәм әһелләренең иңрәүләре", - дип җавап бирделәр. Шуннан соң мине алып киттеләр. Каршымда тубыкларыннан асып куелган, авызлары колакларына кадәр ярылып, авызларыннан елгадай кан аккан кешеләрне күрдем. "Болар кем?" - дип сорадым. "Уразада булып, ифтар вакыты җиткәнче авыз ачканнар", - диделәр"** (Ибн Хузәймә, Ибн Хиббан, Мүнзири, "Әт-Тәргыйб", №1512, 2/116-117).

### УРАЗАНЫҢ ФАРЫЗ БУЛУЫ ШАРТЛАРЫ

1. Мөселман булу.

Мөселман булу шарты - шәригатьнең фикыһка бәйле гыйбадәтләреннән җаваплы булу. Бу очракта кяферләр шәригатькә бәйле гыйбадәтләрдән җаваплы түгел.

Без, хәнәфиләр карашынча, кяфер мөселман булса, аннан кяфер чакта калдырылган уразаларның каза кылынуы таләп ителми.

2. Сәламәт акыллы булу.

Тилегә ураза фарыз кылынмаган. Акылы зәгыйфь кеше ураза әһеле булмаганга, аңа мәрәҗәгать ителмәгән.

3.Балигъ булу.

Балигъ булмаган (бала) кешегә ураза фарыз түгел, чөнки шәригать тәкъдиме балаларга кагылмый.

Яхшыны яманнан аера белгән сәламәт акыллы кыз һәм ир балаларның уразалары, намазда булулары кебек, дөрес санала. Ураза тотарга хәлләреннән килерлек, физик үсешләре мөмкинлек бирерлек булган очракта җиде яшьлек балаларга тәрбия кылган кешеләре тарафыннан уразаның әмер ителүе кирәк. Ун яшен тутырганда аларны ураза тотарга мәҗбүр итәргә кирәк. Баланың ураза тота алуы, ягъни хәленнән килүе, шулай ук, игътибарга лаек шарт.

4. Сугыш кырында мөселманлыкка күчкән кешеләр уразаның фарыз гыйбадәт булуын белергә тиеш.

### УРАЗА ТОТУНЫҢ ШАРТЛАРЫ

1. Хаста булмау.

Хаста кешеләрнең ураза тотулары фарыз түгел. Әгәр ураза тота ала икән, уразасы дөрес була.

Аллаһы Тәгалә әйткән: **"Ураза санаулы көннәр, ягъни ураза ае 29 көннән һәм 30 көннән килә. Арагыздан бергез чирләсә яки сәфәрдә булса, ураза тотмасын. Чирле кеше сәламәтләнгәч, сәфәрдәге кеше өенә кайткач, калган көннәрен бер көн өчен бер көн тотып тәмам итәр. Авырлык белән тотучыларга фидия кирәк: бер көн өчен бер мескенне бер көн ашату. Берәү бер мескен урынына күбрәк мескеннәрне ашатса (яисә фидияне арттырса), артыгы үзенә хәерле. Әмма мескеннәрне ашатып, өстегездән төшергәнгә караганда, ураза тотуыгыз сезнең өчен хәерле, әгәр белсәгез"** ("Бәкара" сүрәсе, 184 нче аять).

Ләкин югарыда искә алынган бер хәдистә: **"Аллаһның рөхсәтен кабул итмәгән кешенең Гарәфәт** (башка бер риваятьтә Өхед) **таулары кадәр гөнаһысы бар"**, - диелгән.

Үлем хасталыгы булган кешенең ураза тотуын дәвам итүе, сәламәтлегенә зыян салуы сәбәпле, аны гөнаһлы итә.

2. Мокыйм булу (бер урында урнашып яшәү).

Сәфәр кылучыларга ураза тоту фарыз түгел. Тоткан очракта уразалары дөрес була. Мәсәлән, ураза тотуларының хәерлерәк булуы югарыдагы аятьтә китерелгән.

"Әшбаһ" дип аталган фикыһ китабында әйтелгәнчә, сәфәрдә ураза тоту артыклык санала, ләкин авырудан курыккан яки ризыклары уртак булган юлдашлары ураза тотмаганда искәрмә була. Ураза мәшәкатьле гыйбадәт, мөсафир өчен аның кичектерелүе рөхсәт ителә.

Ураза тотмауны мөбаһ (рөхсәт ителә торган) кылучы сәфәр, имам Әгъзам (рәхмәтуллаһи галәйһи) фикеренчә, җәяүленең яки кәрван белән баручы дөянең уртача тизлеге белән барганда өч көн һәм өч төн ераклыгындагы юлга тиң. Диңгезләрдә исә, җилкәнле көймәләр белән барып, һава шартлары уртача булганда, унсигез сәгать ераклыгындагы сәфәр була. Кайбер фикыһ белгечләре фикеренчә, сәфәрнең ераклыгы унсигез фәрсаһлык арадан гыйбарәт. Бер фәрсаһ өч мильне тәшкил итә. Һәр миль егерме минутта узыла торган булса, унсигез фәрсаһ унсигез сәгатьтә узылачак. Имам Мәлик белән имам Әхмәд (рәхмәтуллаһи галәйһимә) фикеренчә исә, сәфәрнең озынлыгы уналты фәрсаһны, ягъни кырык сигез мильне тәшкил итә...

3. Хатыннарның күрем һәм нифастан (бала тудырганнан соң килә торган каннан) арынган булулары, ягъни пакъ, чиста булулары.

Күрем яки нифас хәлендә булган хатын-кызларның ураза тотулары дөрес түгел. Күрем яки нифаслы булулары сәбәпле тота алмаган уразаларын рамазан узганнан соң каза кылалар. Бу очракта, укылмый калган намазлары каза кылынмый...

### УРАЗА ТОТУЧЫГА СӨННӘТ ҺӘМ МӨСТӘХӘБ (САВАПЛЫ) БУЛГАН НӘРСӘЛӘР

Йокыдан сәхәргә тору - сөннәт. Моның Коръәни-Кәримдә дәлиле бар:

**"...Сәхәр дә ашагыз, эчегез, хәтта таң якынлыгы беленгәнче, аннары уразаны тотып, тәмам итегез кояш баеганчы!"** ***("Бәкара" сүрәсе, 187 нче аять).***

Ибн Әбү Ләйла (рәхмәтуллаһи галәйһи) болай дигән: "Исламның беренче елларында берәр кеше уразасын бозганнан соң берни дә ашамыйча йокласа, икенче таңга кадәр берни дә ашамаган (сәхәргә тору булмаган). Шулай ук ир үз хатыны белән җенси якынлыкка да кермәгән". Мөгаз Ибн Җәбәл (радыйаллаһу ганһү) болай дигән: Гомәр Ибн Хаттаб (радыйаллаһу ганһү) бер рамазан төнендә хатыны янына килеп, аның белән якынлык кылырга теләгән. Хатыны: "Мин ифтардан соң йокладым", - дигән. Хәзрәти Гомәр (радыйаллаһу ганһү), хатынының ялганламакчы булуын белгәч, аның белән якынлык кылган.

Шулай ук ул төнне әнсарлардан бер кеше ахшам өенә килеп ашарга теләгән. "Сиңа бераз ризык җылытып бирик", - дигәннәр. Ләкин ул шунда ук йоклап киткән, ризыгын да ашамаган. Иртән: **"Рамазан аенда авыз ачканнан соң таңга хәтле хатыннарыгызга якынлык кылу хәләл ителде"** ("Бәкара" сүрәсе, 187 нче аять) дигән аять иңдерелгән һәм имсакка кадәр ашау-эчү, ир белән хатынының якынлык кылулары хәләл ителгән.

### УРАЗА ТОТУЧЫГА МӘКРУҺ (ХУПЛАНМЫЙ ТОРГАН) НӘРСӘЛӘР

**1. Сәбәпсез берәр нәрсәне кабып карау.**

Нәфел уразасы тотканда да бу эш уразаның бозылуына сәбәп булырга мөмкин. **"Тахтави"** дип аталган әсәрдә шушы исем астында бирелгән әлеге мәгълүмат бар.

Хатын-кызның ире рөхсәтеннән башка нәфел уразасы тотуы мәкруһ була. Ләкин ире хаста, уразалы яки хаҗ яисә гомрә ихрамына кергән булса, мәкруһ булмас. Бу очракларда ирнең хатынын уразадан тыюы дөрес булмас.

Тотачак уразасы эшләгән эшендә зыян итә торган булса, эшче эш биргученең рөхсәтеннән башка нәфел уразасы тотмас. Әгәр зыян итмәсә, эш биргученең рөхсәтеннән башка да нәфел уразасы тотуы дөрес булыр.

Бер кешенең кызы, анасы, кыз кардәше аның рөхсәтеннән башка гына нәфел уразасы тота алалар ("Тахтави галә Мәракил Фәлаһ", 559 б.).

Уразалы кешенең бал яки зәйтүн мае сатып алганда, тәмен белү өчен, аларны кабып каравы мәкруһ була. Бер караш буенча, белеп алуы кирәк булса яки алдану куркынычы булса, бугазга кадәр җибәрмәү (йотмау) шарты белән татып караудан зарар юк.

Уразалы кеше суның өчен кереп коенса, бу аның уразасын бозмас. Ләкин мәкруһ булыр ("Фәтава-и Һиндиййә", 1 том, 199 б.).

**2. Сәбәпсез берәр нәрсәне чәйнәү.**

Уразалы бер хатынның баласына ашатачак ризыкны күремле башка бер хатыннан чәйнәттермичә, үзе чәйнәве шуңа охшаш нәрсә була. Әгәр мондый мөмкинлек булмаса һәм уразалы хатын ризыкны үзе чәйнәргә мәҗбүр булса, баласын саклау максатыннан, моны үзе эшләү: бернинди дә зыян булмас.

Хатын-кызның ире холыксыз кеше булып, пешергән ризыгының тәмен белү өчен, аны татып каравы рөхсәт ителә ("Тахтави галә Мәракил Фәлаһ", 559 б.)

**3.Шикәре булмаган сагызны чәйнәү.**

Бу сагызның бернәрсәсе дә төкерек белән бергә ашказанына китмәскә тиеш. Бу очракта хатыннарның да, ирләрнең дә хәлләре бертигез. Уразалы булмаган чакта хатыннарның сагыз чәйнәүләре мөстәхәб. Ирләр өчен бу мәкруһ гамәл була. Ләкин берьялгызы гына калганда сагыз чәйнәве мәкруһ булмас.

**4.Ураза тотучының хәләлен үбүе дә мәкруһ.**

Бушану яки җенси якынлык кылмаячакларыннан ышанычлары булмаса, ураза тоткан кешенең хатынын үбүе һәм башкача дәвам итәчәк мөнәсәбәте мәкруһ була. Чөнки болар уразаның бозылуына сәбәп булырга мөмкин. Ләкин үзләренең гамәлләреннән имин булсалар, моның бернинди зыяны юк...

Әбү Һурайра (радыйаллаһу ганһү) әйткән: "Рәсүлуллаһтан (саләллаһу галәйһи вәссәләм) бер яшь кеше, ураза тоткан чакта үбәргә ярыймы, дип сораган. Аңа Пәйгамбәребез "үбәргә ярамый" дип җавап кайтарган. Бер карт кеше шушы ук сорауны биргәч, аңа "ярый" дигән һәм: "Яшьләр картлар белән бер түгел", - дип тә өстәгән (Табәрани, Әвсад, Хәйсәми, №4963, 3/388-389).

**5. Уразалы кешенең истинҗа кылганда арттырулары мәкруһ.**

Чөнки тәһарәтләнгән чакта арттырып, чиктән узып, арт юлга суны эчкә кертеп юыну суның күп тотылуына сәбәп кенә була. Шулай ук тәһарәнләнгәндә авызны чайкау һәм борынны су белән юдыруда арттырып җибәрү дә мәкруһ була.

**6. Төкерекне авызда махсус җыеп, аннары аны йоту мәкруһ.**

Моның мәкруһ булуы, уразалы кешене шик-шөбһәдән арындырудан гыйбарәт.

**7. Кан алдыру, авыр эш кебек үзен ураза тотканда хәлсезләндерергә мөмкин нәрсәләрне кылу мәкруһ.**

**8. Ураза тотачак кешенең мөмкин булган хәлдә җенси якынлыктан соң төнлә юынмыйча иртән торуы да мәкруһ ("Фәтава-и Һиндиййә", 1 том, 199 б.);**

### УРАЗАЛЫ КЕШЕГӘ МӘКРУҺ БУЛМАГАН НӘРСӘЛӘР

**1. Бушану һәм җенси якынлыкка барып җитмәячәкне белеп үбешү яки кочаклашу.**

Гаишә (радыйаллаһу ганһә) әйткән:

**"Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм) уразалы чакта (хатыннарын) үбә һәм (алар белән) шаярыша торган иде"** (Бохари, "Саум", 23, №1826, 2/680; Мөслим, "Сыйам", 12, №2576, 450 б.; "Тахтави галә Мәракил Фәлаһ", 560 б.).

**2. Мыекларга май сөртү.**

Бу гамәлдә уразаны бозарлык берни дә юк.

3. Күзгә сөрмә тарту.

Әбү Рафигъ (радыйаллаһу ганһү) тапшырганча: **"Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм) ураза тотканда күзләренә сөрмә тарта иде"** (Табәрани, "Әл-Мугҗәмүл Кәбир"; Хәйсәми, "Мәҗмәгуз Зәваид", №4971-4972, 3/391).

Ләкин күзгә сөрмә тарту бизәнү дигән сүз түгел. Бу очракта бизәнү мәкруһ була.

**4. Көннең башында яки ахырында мисвәк куллану мәкруһ түгел.**

Киресенчә, мисвәк куллану сөннәт гамәл була. "Кифайә" исемле әсәрдә бу хакта болай диелгән:

Әбү Һурайра (радыйаллаһу ганһү) риваять иткән бер хәдистә Рәсүлуллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм): **"Мисвәк - сөннәт. Мисвәкне көндез үзегез теләгән вакытта кулланыгыз"**, - дип әмер иткән (Әбү Нугайм, "Хилйәтул әүлия", 3/49; Дәйләми, Фирдәүс, Нәбхани, "Әл-Фәтхул Кәбир", №7044, 1/649).

**5. Уразалы кешене хәлсезләндермәгән очракта кан алдыру мәкруһ түгел.**

Мәсәлән, Ибн Габбас, Әнәс һәм Мөгаз Ибн Җәбәл (радыйаллаһу ганһүмә) тапшырганча: "Рәсүлуллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм) рамазан аенда ураза тотканда икендедән соң кан алдырган иде" (Әбү Дауд, "Сыйам", 29, №2372-2375, 344-345 б.; Бәззар, №1011, 1014; Табәрани, "Әл-Мугҗәмүл Кәбир", 20/93; Хәйсәми, "Мәҗмәгуз Зәваид", №4995-4999, 3/397).

Ислам шәехләре уразалы чакта кан алдыруның хәлсезләндергә китерү ихтималын сәбәп итәләр. Уразалы кеше кан алдыра торган булса, моны кояш бату вакытына кадәр кичектерсә яхшырак булыр, диләр.

**6. Тәһарәт алмаганда авызны чайкау һәм борынны су белән юдыру мәкруһ түгел.**

**7. Гәүдәне суытып җибәрү өчен су коену яки юеш тукыма белән сөртенү, фәтвага нигез булган караш буенча, мәкруһ түгел.**

Әбү Бәкер Ибн Абдиррахман (радыйаллаһу ганһү) бер сәхабәнең әйткәннәрен тапшырган: **"Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм) гәүдәсен суытып җибәрү өчен яки уразалы чакта сусавын басу өчен башына су коя иде"** (Әбү Дауд, "Сыйам", 27, №2365, 344 б.).

# Уразага кайчан керәбез?

**Татарстан мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН ТҖ МДН Галәмалар шурасы карары нигезендә рамазан ае башлану көнен, фитыр һәм фидия сәдакасы күләмнәрен раслады.**

Быел рамазанның беренче көне 28 нче июньгә туры килә, беренче тәравих намазын Татарстан мәчетләрендә 27 нче июньнән укый башлыйлар. Ураза бәйрәме 28 нче июльгә туры килә, Корбан бәйрәме 4 нче октябрьдә була.

Фитыр сәдакасы күләме - 50 сум, зәкят чыгарырлык мөмкинлеге булганнарга - 330 сум. Сәламәтлеккә бәйле рәвештә ураза тота алмаган көннәр өчен фидия күләме һәр көн өчен - 330 сум. Сәдака күләмнәре Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) сүзләренә таянып һәм агымдагы елда он, хөрмә һәм йөзем бәясенә карап билгеләнә.

Рамазан аенда ураза тота алмаган кешеләр уразаларын башка айларда тота ала, уразаны бөтенләй тота алмаганнар исә фидия сәдакасы түли.

Рамазан аенда фитыр сәдакасы билгеләнә. Фитыр сәдакасы бирү һәр мөселманга да важиб гамәлләрдән санала. Фитыр сәдакасы мохтаҗларга бирелә. Аны мөселман булмаганнардан һәм фәкыйрьләрдән тыш, бар кеше дә бирергә тиеш. Фитырны гаилә башлыгы барлык гаилә әгъзалары һәм аның тәрбиясендә булган кешеләр өчен үзенең кеременнән түли. Ир бала балигъ булуга, фитырны үзе өчен үз кеременнән түләргә омтылырга тиеш. Андый мөмкинлеге булмаган очракта, бу бурыч гаиләдәге башка иратлар өстенә төшә.



# Ифтар ашларына килегез

**Җөмһүриятебездә бер күркәм традиция яшәп килә: мөселманнар ифтар ашларын гаиләләрендә, туган-тумачалары арасында гына түгел, мәчет-мәдрәсәләргә күбрәк мөселманнарны җыеп та уздыралар. Көне буе ураза тотканнан соң, бергәләшеп авыз ачуның, вәгазьләнүнең, җәмәгать белән тәравих намазы укуның аерым бер рәхәтлеге бар.**

Быел Казанның кайсы мәчетләрендә ифтар ашлары уздырыла икән?

*1. Мәрҗани мәчете (адресы - Каюм Насыйри ур., 17 нче йорт). Ун еллык традицияне дәвам итеп, мәчет ишегалдындагы чатырда быел да ай дәвамында 350 кешелек табын әзерләнәчәк.*

*2. Ярдәм мәчетендә (Серов ур., 4а йорт) ай дәвамында 200 кеше өчен ифтар мәҗлесләре оештырыла.*

*3. Гаилә мәчетенең (Җ.Фәйзи ур., 2 нче йорт) 250 кеше сыйдырышлы залында ай дәвамында ифтар ашлары уздырылыр дип ниятләнелә.*

*4. Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәдә (М.Гафури ур., 67 нче йорт) 20-70 ләп ураза тотучы дин карндәшебезгә ифтар ашы әзерләнә.*

*5. Хузайфа мәчетендә (Юлиус Фучик ур., 53 нче йорт) ай дәвамында ифтар ашлары уздырырга җыеналар.*

*6. Ризван мәчетендә дә (Хөсәен Мәүлетов ур., 48а йорт) шулай ук ай дәвамында 100 кешелек ифтар табыннары корылачак.*

*7. Рамазан мәчетендә (Окольная ур., 25б йорт) алдагы еллардагыча 60-70 кешелек 25 ләп ифтар мәҗлесе уздырылачак, иншә Аллаһ.*

*8. Нурулла (Мәскәү ур., 74/15 нче йорт) һәм Кабан арты (һ.Такташ ур., 26 нчы йорт) мәчетләрендә дә, мөрәҗәгать итүчеләр булса, ифтар ашларын уздырырга әзер булуларын белдерделәр.*

*Башка мөхтәсибәтләрдә дә мөселманнар, зур табыннар корып, ифтар мәҗлесләре уздырырга әзерләнәләр. "Мәчетләребездә көн саен диярлек ифтар ашлары үткәреләчәк, иншә Аллаһ",- диделәр безгә Чаллы мөхтәсибәтеннән. Буа мөселманнары исә аларны ай дәвамында Хаҗилар, Госман, Мәлик мәчетләрендә һәм мәдрәсәдә уздырырга җыеналар. Кукмараның Хәйрия мәчетендә, барлык авыл мәчетләрендә көн саен мәҗлесләр үткәреләчәк. "Мин бу эш белән артык мавыкмаска кушам, чөнки вакыты бик соң бит, - ди Татарстанның баш казые, Балтач мөхтәсибе Җәлил хәзрәт Фазлыев. - Өйләрендә туган-тумачалары белән җыелып уздыруны хуплыйм. Шулай да җамигъ мәчетендә - 4-5 тапкыр, авылларда да уздырылачак, иншә Аллаһ". Мамадыш мөхтәсибәтендә ифтар ашлары уздыруның графигы инде күптән төзелгән. Районның һәр мәчетендә алар мөхтәсибәт вәкилләре һәм коръәнхафизлар катнашында уздырыла. Шулай ук шәһәрнең 3 мәчетендә һәм мәдрәсәдә (көн саен диярлек), предприятиеләрдә, авыл мәктәпләрендә һәм Шәһәр ифтары үткәрергә ниятлиләр.*

*Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгалә тоткан уразаларыгызны кабуллардан кылсын, уздырган ифтарларыгызның савапларын бирсен!*

# РАМАЗАН – КОРЪӘНИ-КӘРИМ ИНДЕРЕЛГӘН АЙ

**Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдулилләәһи раббил гааләмииин вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил кәрим үә галәә әәлиһи үә әсхабиһи әҗмәгыйн.**

Рамазан сүзе рамаз, ягъни "кыздыра, көйдерә торган эсселек" сүзеннән алынган, шулай булгач, рамазан - барлык гөнаһларны яндыру, юкка чыгару ае дигән сүз. Кәгъб бин Уҗра исемле сахабә (Аллаһ аннан разый булса иде) түбәндәгеләрне җиткергән: "Бер көнне Аллаһның рәсүле галәйһиссәләм үзенең сахабәләренә: "Мөнбәр янына килегез", - диде. Без килдек. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм мөнбәрнең беренче баскычына менгәч: "Әмин", - дип әйтте. Мөнбәрнең икенче баскычына менгәч: "Әмин", - дип әйтте һәм өченче баскычка менгәч янә: "Әмин", - дип әйтте. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм хөтбәне сөйләп бетергәннән соң аска төште, без аңа: "Бүген сездән элек ишетмәгән нәрсәләрне ишеттек", - дип әйттек. Ул (с. г. в.) безгә болай диде: "Минем яныма Җәбраил галәйһиссәләм килде һәм мин мөнбәрнең беренче баскычына менгәч, ул: "Рамазан аен кушы алып, гөнаһлардан котыла алмаган кеше хәсрәттә булыр", - диде. Шул вакытта мин: "Әмин", - дидем. Мөнбәрнең икенче баскычына менгәч, Җәбраил галәйһиссәләм: "Синең мөбарәк исемеңне ишетеп салават әйтмәгән кеше хәсрәттә булыр", - диде. Мин янә: "Әмин", - дидем. Мөнбәрнең өченче баскычына менгәч, ул: "Ата-ананың картлык көннәрен күреп, алар аша җәннәткә кермәгән кеше хәсрәттә булыр", - диде. Мин, янә: "Әмин", - дидем" (Бохари).



Әлеге хәдистә әйтелгәнчә, рамазан аенда көннәрне - уразасыз, төннәрне - гыйбадәтсез, догаларсыз үткәргән кеше зур хәсрәттә булыр.

Рамазан-шәриф - Аллаһның Китабы Коръәни-Кәрим иңгән ай, ягъни Коръәнне уку, өйрәнү, аның аятьләре, сүрәләре турында уйлау, фикер йөртү һәм, әлбәттә, Коръән буенча яшәү ае.

Аллаһы Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә: "Рамазан ае - кешеләргә тугры юл күрсәтүче, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән индерелә башлаган айдыр" ("Бәкара (Сыер)" сүрәсе, 185 нче аять).

Коръән укуның фазыйләтләре турында сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәләм үзенең бер хәдисендә болай дигән: "Коръән укыгыз, чөнки Аллаһның Китабыннан укылган һәрбер хәреф өчен ун савап биреләчәк, мин "Әлиф-ләм-мим" бер хәреф дип әйтмим, чөнки аларның һәрберсе - аерым хәреф, аларның барысы өчен дә унар савап биреләчәк" (Тирмизи).

Әбү Һөрайра исемле сахабә (Аллаһ аннан разый булса иде) риваять кылганча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәләм әйткән: "Әгәр бер кеше мөселман кардәшен бер кайгысыннан арындырса, Кыямәт көнендә Аллаһ ул бәндәне бер кайгысыннан арындырыр. Әгәр бер кеше бер фәкыйрьнең хәлен җиңеләйтсә, Аллаһ аның хәлен бу дөньяда да һәм ахирәттә дә җиңеләйтер. Бер кеше үзенең кардәшенә ярдәм иткәндә Аллаһ аңа Үзенең ярдәмен дә ирештереп торыр. Гыйлем алу юлына баскан кешегә Аллаһ җәннәт юлын җиңеләйтер. Кешеләр, Аллаһ йортына җыелып, Аның Китабын укыганда мөселманнарның җаннарына тынычлык иңәр, алар бәрәкәтле булыр вә фәрештәләр алар өстендә канатларын җәеп торыр. Алар Аллаһы Тәгаләгә якын булыр" (Мөслим, Әбү Дауд, Тирмизи, Ибн Мәҗә).

Әгәр мөселман кешесе көндез ураза тотса, төннәрен - Коръән укыса, Кыямәт көнендә аның ике яклаучысы булачак. Алар мөселманнарга Аллаһтан ярлыкау һәм җәһәннәм утыннан котылу сораячак.

Ибн Габбас (Аллаһ аннан разый булса иде) риваять кылган: "Җәбраил галәйһиссәләм рамазан аеның һәр төнендә Пәйгамбәребез галәйһиссәләм белән очрашып, аның белән бергә Коръән өйрәнгән" (Бохари, Мөслим).

Кадерле мөселманнар! Аллаһ Раббыбыз безгә дә рамазан аеның төннәрендә уяу торып, Аллаһның Китабын укып, Аның бетмәс-төкәнмәс әҗер-савапларына ирешергә насыйп итсә иде.

Рәсүл Әкрам салләллаһу галәйһи вәссәләм икенче бер хәдисендә болай дигән: "Ике төрле кешедән генә көнләшергә ярый: беренчесе - Аллаһы Тәгалә Коръән байлыгы биреп, шуның белән көн-төн мәшгуль булучыдан; икенчесе - Аллаһы Тәгалә күп нигъмәтләр биреп, шул байлыгын изге юлда сарыф итүчедән" (Бохари, Мөслим).

Аллаһ Раббыбыз һәрбарчаларыбызга да Коръән буенча яшәп, ике дөньяда да бәхет-сәгадәткә ирешүчеләрдән булырга насыйп итсә иде.

*Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге*

### УРАЗАГА НИЯТ ДОГАСЫ

Сәхәр ашаганнан соң уразага таң атканчы ният кылу - мөстәхәб (саваплы). Ураза тоту өчен күңел белән ният кылу җитә. Түбәндәге доганы укып, тел белән ният кылу мөстәхәб санала: "Нәүәйту ән әсуумә саумә шәһри рамадаанә минәл-фәҗри иләл-мәгриби хаалисан лилләәһи тәгаалә (Аллаһы Тәгалә өчен ихласлык белән таң вакытыннан башлап кояш батканчыга кадәр рамазан уразасын тотарга ният кылдым)".

### ИФТАР ДОГАСЫ

Кояш баткач, көнлек уразаны тәмамлаганда ризык, тоз яки су белән ифтар кылу, ягъни авыз ачу сөннәт санала. Хөрмә кебек татлы җимешләр белән ифтар кылу мөстәхәб.

Ифтардан соң (авыз ачканнан соң) түбәндәге дога укыла: "Әллааһүммә ләкә сумту үә бикә әәмәнту үә гәләйкә тәүәккәлту үә гәләә ризкикә әфтарту фәгфирлии йәә гаффару мә каддәмту үә мәә әххәрту (Аллаһым, шушы уразамны Синең өчен тоттым һәм Сиңа гына иман китердем һәм Сиңа тәвәккәл иттем. һәм Синең ризыгың белән авыз ачам. Әй гөнаһларны гафу итүче Аллаһым, минем әүвәлге гөнаһларымны да, соңгы гөнаһларымны да ярлыка)".

# ТӘРАВИХ НАМАЗЫ

1. Рамазан аенда һәр көнне ястү намазыннан соң витр намазына кадәр тәравих намазын уку ирләргә дә, хатыннарга да сөннәт.

2. Тәравих намазы бары 20 рәкәгатьтән тора. Икешәр рәкәгать ун намаз итеп яки дүртәр рәкәгать биш намаз итеп укыла. Бу намаз ялгыз да укыла, әмма җәмәгать белән мәчеттә уку сөннәт санала.

3. Тәравих намазын җәмәгать белән укыганнан соң витр намазы да җәмәгать белән укыла. Имам тәравих намазының да, витрның да кыйраәтләрен кычкырып укый.

4. Тәравих намазына түбәндәгечә ният кылалар: "Ният кылдым ике рәкәгать тәравих намазын үтәмәккә, оедым ошбу хазир (алда торган) имамга, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр".

5. Тәравих намазында дүрт рәкәгать укыган саен, дүрт рәкәгатьле намаз укыган кадәр вакыт туктап "тәравихә" кылу, ягъни ял итеп тору сөннәт.

6. "Тәравихә" вакытында я тәсбих, я тәһлил ("Ләәә иләәһә илләллаһу" ("Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга һәм табынырга лаеклы һичбер илаһ (зат) юк") дип) әйтеп яки әйтелгәнне тыңлап утыру мөстәхәб.

7. Без яши торган төбәктә "тәравихә" вакытында түбәндәге тәсбих әйтелә: "Субхәәнә зилмулки үәл-мәләкүүт. Субхәәнә зил-гиззәти үәл-гәзамәти үәл-кудрәти үәл-кибрийә'и үәл-җәбәрүт. Субхәнәл-мәлики-хәййил-ләзи лә йәмүт. Суббухун куддүүсүр-раббил-мәләә'икәти үәр-руух. Ләә иләәһә ил-ләллаа һу нәстәгфирул-лаах. Нәс'әлүкәл-җәннәтә үә нәгүүзү бикә минән-наар (Җирдәге һәм күктәге мәхлукатның (җан ияләренең) хуҗасы булган Аллаһы Тәгаләне данлыймын. Көч, кодрәт һәм бик олуглык иясе булган Аллаһы Тәгаләне данлыймын. Бөтен галәмнең патшасы һәм беркайчан үлмәячәк, һәрвакыт терек булучы Аллаһы Тәгаләне данлыймын. Ул Аллаһы Тәгалә бөтен кимчелекләрдән бик пакь һәм мөкаддәс Зат, бөтен фәрештәләрнең һәм Җәбраил фәрештәнең Раббысы. Бер Аллаһы Тәгаләдән башка илаһи зат юк. Без гөнаһларыбызның ярлыкавын сорыйбыз. Йә, Рабби, без Синнән җәннәтне сорыйбыз һәм тәмугтан Сиңа сыгынабыз)".

8. Тәравих намазлары тәмам булып, бишенче тәсбих әйтелгәннән соң түбәндәге дога укыла: "Әллааһүммә салли гәләә Мүхәммәдин үә гәләә әәли Мүхәммәдин үә сәллим. Әллааһүммә зәййиннәә бизиинәтил-иимән. Үә шәррифнәә бишәрааф-әтил-һидәәйәти үәл-гирфәән. Үә әкримнәә бисыйәами шәһри рамәдаан. Үәр-зүкнәл-җәннәтә үәл-гуфраан. Үә тәкаббәл миннәә тәрааүиихәнәә йәә сүбхәән. Үәстәҗиб дугааәнәә йәә хәннәән. Бифдыликә үә җүдикә йәә мәннаан. Бирәхмәтикә йәә әрхәмәр-рахимиин (йә, Рабби, Мөхәммәд галәйһиссәләмгә, аның әһеленә (гаиләсенә), рәхмәтеңне һәм сәламеңне бир. Йә, Рабби, безне иман зиннәте белән зиннәтлә, гыйлем һәм тәүфыйк белән кадерлә һәм рамазан ае уразасы белән хөрмәтле ит. Безгә җәннәтне һәм ярлыкауны насыйп ит. Әй пакь булучы Аллаһ, безнең тәравих намазларыбызны кабул кыл, әй Рәхмәтле Раббыбыз һәм сорамыйча бирүче Аллаһ, фазыйләтең һәм юмартлыгың белән догаларыбызны кабул кыл. Әй камил рәвештә Рәхмәтеңне бирүче Аллаһ, һәрнәрсә Синең рәхмәтең белән генә була)".

9. Тәравих намазының һәр рәкәгатендә "Фатиха" сүрәсеннән соң бер кыска сүрә укыла. Коръәннең башыннан алып, һәр рәкәгатендә куша-куша, берничә тәравихта ахырына кадәр укып чыгып, Коръәнне хәтем кылу (тулысынча уку) олуг сөннәт булып тора.

10. Тәравих намазын ястү намазын укыганнан соң уку - сөннәт, шуның өчен мәчеткә тәравих намазы укыла башлагач килгән кешегә, иң әүвәл ялгызы гына ястү намазының дүрт рәкәгать фарызын уку һәм аннан соң тәравих намазына ниятләп, имамга ою тиешле.

11. Намазга соңарган кеше тәравихның калган рәкәгатьләрен имамнан соң ялгыз укып тәмамлый. Әгәр имам витрны укып бетергәнче тәравихны тәмамласа, имамга мәсбук булып ойый. Әгәр тәравихны тәмамлаганчы имам витрны укып бетерсә, витрны да ялгыз укый.

*Әхмәтһади Максудиның "Гыйбадәте исламия" китабыннан*

---

**Мәсбук - намазның иң аз дигәндә бер рәкәгатен калдырган һәм беренче рәкәгатьнең рөкүгыннан соң гына кушылган кеше. Ул имам ике якка "сәлам" биргәннән соң торып баса һәм намазның үтәлми калган өлешләрен, кыйраәт рөкенен үтәп, укып бетерә.**

# АЛЛАҺКА ШӨКЕР ИТҮ, КЫЛУ ӨЧЕН

**Көне буе яңгыр сибәләп торуга карамастан, Изге Болгар җыенына 30 меңнән артык кеше килгән иде. Казан, Мәскәү, Самара, Чиләбе, Волгоград... Россиянең төрле төбәкләрендә яшәп ятучы татарлар ул көнне әби-бабаларыбыз ислам динен кабул иткән, безнең өчен мөкатдәс булган шәһре Болгарга җыйналды. Әйе, Болгар - уртак тарихыбыз да, үткәнебез дә, бүгенгебез дә. Ул безне киләчәктә дә милләт буларак берләштереп, җәмәгать итеп ислам динендә туплап торыр, иншә Аллаһ.**

Халык Казан, Мәскәү калаларыннан килгән олы кунакларны ислам динен кабул итүгә Истәлек билгесе буларак төзелгән бина каршындагы мәйданда каршы алды. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Җөмһүрияте мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать Таҗетдин, Россиянең Европа өлеше мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Равил Гайнетдин, ТР хөкүмәте Рәисе Илдар Халиков, Казан шәһәре мэры Илсур Метшин, БДБ мөселманнарының консультатив советы рәисе Пашазадә Аллаһшөкер, Казахстан, Кыргызстан, Украина, Белоруссия һәм башка илләрнең мөселманнары лидерлары бирегә Болгарның Ак мәчетендәге конференцияләр залында булган очрашудан соң килде.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов республика җитәкчелеге исеменнән Җыенда катнашучыларны бәйрәм белән тәбрикләде. "Болгар җирлеге динебезне саклауга зур өлеш кертә", - дип ассызыклап, Рөстәм Миңнеханов Болгар шәһәрен торгызуда катнашкан затларга - җитәкчеләргә, төзүчеләргә, дин әһелләренә, тарихчыларга, археологларга, иганәчеләргә рәхмәт сүзләре әйтте. "Бәйрәмебез матур булсын! Аллаһы Тәгалә ярдәменнән, рәхмәтеннән ташламасын! Шушы җирлектә ел саен очрашырга насыйп булсын!" - дигән теләкләрен дә җиткерде.

"Бәйрәм кунаклар белән ямьле. Бернигә карамастан, бәйрәмгә килгәнегез, яңгыр китергәнегез өчен рәхмәт. Ходайга шөкер, күптән көтелгән яңгыр ява, Аллаһы Тәгалә гамәлләребезне кабул итәдер, дип өметләник", - дип башлады сүзен Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев. Аннары ул Болгарның хөкүмәт, халык ярдәме белән торгызылганлыгын билгеләп үтте һәм: "Кунакларны бирегә төрле транспорт, уңайлы юллар белән китерү мәсьәләсе өстендә эш алып барыла. Зур чыгымнар кирәк булса да, һичшиксез, хәл ителер", - диде.



Югары мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдин үз чыгышында ил күләмендә дини яңарыш хакимлек итүен, Россиядә 7,5 меңләп, ә Татарстанда 1,5 мәчет гамәлдә булуын искәртеп үтте. "Изге Болгар җыены мөбарәк булсын! Без бирегә Аллаһка шөкер кылу, ата-бабаларыбызны дога белән искә алу өчен җыелдык. Бөтен дөньяга үрнәк булган бу изге эшебезгә Аллаһ тагын да куәт өстәсен!" - диде Тәлгать хәзрәт.



Бәйрәмдә катнашучыларны шулай ук мөфти Равил хәзрәт Гайнетдин, БДБ мөселманнарының консультатив советы рәисе Пашазадә Аллаһшөкер тәбрикләде. "Безнең бурычыбыз - ата-бабаларыбыздан килгән динебезне күз нурыдай сакларга кирәк дигән васыятьне балаларыбызга да сеңдерү", - дип белдерде Равил хәзрәт Гайнетдин үзенең чыгышында.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, җыелган халыкка мөрәҗәгать итеп, динебез кушканча яшәргә һәм бердәмлеккә чакырды. "Аллаһка шөкер, бүген янә борынгы бабаларыбыз җирен зиярәт кылырга, аларның рухларына багышлап дога кылырга җыелдык. Мөхтәрәм җитәкчеләр, дин әһелләре, галимнәр һәм меңләгән мөселман кар-

# ҖӘМӘГАТЬКӘ ТУПЛАНГАН МӨСЕЛМАН АДАШМАС

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә*

Аллаһы Тәгалә Коръәннең хакыйкый булуын саклый. Без исә ислам динен сакларга һәм таратырга тиеш. Пәйгамбәребез (с.г.в.) бер хәдисендә: "Туры юлга баскан милләт, әгәр араларында аерымлык һәм таркаулык барлыкка килмәсә - азмас"- дигән. Динне саклау - һәрбер мөселманның көн саен үтәлергә тиешле изге бурычы ул.

Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) янә бер хәдисе бар: "Биш нәрсәне танымаган - биш нәрсәне югалтыр: галимнәрне танымаган - динен; идарәчеләрне танымаган - дөньяны; күршеләрен танымаган - файдасын; гаиләсен танымаган - рәхәт гомер кичерүне; дустын танымаган - үз кадерен". Татарларга менә шундый югалтуларсыз яшәргә язсын!"

Россиянең Европа өлеше мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Равил Гайнетдин форумны оештыручыларга рәхмәт әйтте. Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты карамагында Бөтенроссия татар дин әһелләре форумының Координацион советын оештыруны хуплады, җәмгыятьтә имамнарның тотарга тиешле роле хакындагы фикерләре белән уртаклашты.

Россия мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте рәисе Тәлгать Таҗетдин дин әһелләрен сәламләп, шулай ук форумны оештыручыларга рәхмәтләрен җиткерде. Илдә тәртип гаиләдән башлана, гаиләдә тәртип булмаса, илдә дә шул хәл, дип гаилә кыйммәтләренә, никах ныклыгына игътибарны юнәлтте. Имам да ата, ул - авыл атасы, һәрхәлдә, шундый дәрәҗәгә җитәргә тиеш, чөнки җәмгыять тә - гаилә, дип фикерен мисалларда нигезләде.

Җыенда Татарстан Җөмһүрияте мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батыр Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең социаль проектлары белән таныштырды. Нәзарәт быел "Дөньяны бергәләп яхшыртабыз!" дип аталган яңа проектны тормышка ашыра. Мәрхәмәтле булырга, изгелек кылырга чакырган 40 кыска метражлы фильм һәм видеоролик әзерләнә. Әлеге роликлар туган җирне, гаиләңне яратырга, милли гореф-гадәтләрне сакларга да өнди. "Социаль ислам идеясе ул, проект кына түгел. Без аны курыкмыйча татар халкының дини, яңа үсеш юлы дип атый алабыз. Бу идеяне тормышка ашыру татарларга Россия мөселманнары арасында интеллектуаль-рухи сферада лидерлыкны сакларга ярдәм итә. Социаль ислам ул - безнең, җәдитче бабайлар кебек үк заман белән бергә баруыбызны, алай гына түгел, күп дин кардәшләребездән бер адым алга китүне күрсәтә торган бер ноу-хау", - диде мөфти урынбасары үзенең чыгышында.

Бөтенроссия татар дин әһелләре форумының быелгысы имамнарның актив катнашында, эшлекле төстә үтте. Алар күтәргән проблемалар, тәкъдимнәрнең кайберләре форум кабул иткән Резолюциягә дә кертелде:

- Болгардагы Ак мәчет комплексында Болгар ислам мәгариф үзәген оештыру башлангычын хупларга;
- Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Россия ислам институтының уңай тәҗрибәсен кулланып, бердәм мөселман мәгариф системасын төзү эшен активлаштырырга һәм Россия төбәкләрендәге татар яшьләрен Татарстандагы дини уку йортларына җәлеп итәргә;
- мөселман җәмәгатьчелегендә радикальләштерү һәм таркату омтылышларына каршы торырга, Россия мөселман өммәтендә үзара аңлашу һәм килешүнең уртак нигезләрен булдырырга;
- Россия кануннарын истә тотып, мөселман оешмаларына күчемсез милек һәм җирне үзләренә беркетү буенча, үзүзләрен яшәтү һәм тәэмин итү системасын булдыру максатында дәвамлы эш алып барырга;
- рухи мираска нигезләнгән татар гаиләсе кыйммәтләрен бөтен яклап ныгытырга, пропагандаларга һәм яңадан торгызырга;
- хәләл индустриясен үстерү максатыннан, Россия Федерациясеннән җитештерүчеләрне, эшмәкәрләрне җәлеп итәргә. Хәләл ризыкларның бердәм сертификация стандартларын кертү мәсьәләсен куярга;
- "ТНВ - Планета" телеканалында ислам дине турында даими тапшырулар алып барырга һ.б.

Форум делегатлары икенче көнне Изге Болгар җыенында да катнашты.

# БАБАЛАРЫБЫЗ РУХЫНА ДОГА ЯНӘ БОЛГАРГА ҖЫЕЛДЫК







дәшләребез - барчабыз бер җәмәгать булып туплandык. Безне бүген бергә җыйган Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгаләгә барлык мактауларыбыз булса иде. Без үз тарихыбызны һәм мәдәниятебезне, бабаларыбызның гореф-гадәтләрен, рухи байлыгыбызның кадерен белергә тиеш. Болгар җирендәге һәрбер ташның күпгасырлык тарихы бар, гыйлемгә омтылыш кына яшәешнең мәгънәсенә төшенергә, тарихи мирасыбызны сакларга ярдәм итәчәк", - диде Татарстан Җөмһүрияте мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Изге Болгар җыенының тантаналы өлешенә йомгак ясап.

Чыгышлардан соң бәйрәм концерт белән дәвам итте. Анда мөнәҗәтләр, борынгы татар җырлары башкарылды, коръәнхафизлар чыгыш ясады. Җыен кысаларында рәсми затлар елга вокзалы янында "Болгар шәһәре урта гасыр һөнәрчелеге" интерактив экспозициясе белән таныштылар, "Сувар" һәм "Биләр" күргәзмә павильоннарын карадылар, "Габдрахман сәхабә коесы" комплексына, дөя фермасына барып килделәр. Аннан соң барча мөселманнар белән күмәкләшеп җамигъ мәчете мәйданчыгында өйлә намазын укыдылар.

***

Изге Болгар Җыенында "Хузур" нәшрият йорты беренче тапкыр китап ярминкәсе уздырды. Җыенга килгән кунакларыбыз татар, гарәп, рус телләрендә язылган дини басмалар белән таныша һәм аларны сатып ала алды.

Ярминкәдә "Хузур", "Иман", "Рисалә", "Умма", "Мир" һәм башка нәшриятлар нәшер иткән китаплар, видеоаудиодисклар тәкъдим ителде. Дини китаплар сату оештырылган чатырдан көне буе халык өзелмәде. Дини китап ярминкәсе бабаларыбызның ислам динен рәсми төстә кабул итүгә багышлап үткәрелә торган Изге Болгар җыенын рухи яктан тагын да баеткандыр, чөнки Россиянең төрле төбәкләреннән җыелган кардәшләребезнең Болгардан үзләре белән ислам дине үсешенә өлеш керткән татар галимнәре китапларын алып китүләре вакыйгага тиң күренеш бит.





# МӨСЕЛМАННАРНЫҢ

### АЛЛАҺ ҺӘМ АНЫҢ КОЛЛАРЫ КАРШЫНДАГЫ БУРЫЧЛАРЫБЫЗ

Безне Үзенең коллары итеп яралткан һәм Үз нигъмәтләре белән яшәешебезне тәэмин иткән Раббыбызга чиксез мактауларыбыз.

Бар мөэминнәргә үрнәк итеп күндерелгән Мөхәммәд пәйгамбәргә (салләллаһу галәйһи вәсәлләм), аның гаиләсенә һәм сәхабәләренә Аллаһның сәламе һәм ярлыкавы ирешсә иде!

Үзләренең гакыллары һәм күңелләре белән бөек вә мөбарәк динебезне күтәргән һәм безгә тапшырган исламның бар галимнәренә дә Аллаһның рәхмәте ирешсә иде.

Аллаһ безне хак һәм туры юлдан аермасын.

Фикер йөртергә сәләтле булган һәркем, бу дөньядагы барлык нәрсәләрнең шулкадәр камил булуын күреп, аларның ниндидер бер сәбәп һәм зирәклек белән, ниндидер бер максатларда яралтылуы турындагы фикергә киләчәк. Ә бу исә бар яралтылганнар арасында иң камиле, иң лаеклысы - кешенең дә ниндидер билгеле бер максат белән яралтылуы турында сөйли. Аллаһы Тәгалә кешеләр турында Коръәндә менә нәрсәләр әйтә: **"Әллә адәм баласы үзенә Аллаһтан йөкләмә йөкләтелмәүне, Аллаһка каршы эшләрдә ихтыярга куелуны һәм ахырда җавапсызлыкны телиме?"** ***("Кыямәт" сүрәсе, 75:36).***

Чынлап та, кеше тулысынча үз иркенә куелмаган. Аның күптөрле бурычлары бар. Бу бурычларны ике төргә бүләргә була:

1. Кешенең Аллаһ каршындагы бурычлары - "Хокукуллаһ".

2. Кешенең башка кешеләр алдындагы бурычлары - "Хокукул-гибәәд".

Намаз уку, ураза тоту, хаҗ кылу кебек бурычларыбыз безнең Аллаһ каршындагы бурычларыбыз булып исәпләнә. Ә үз сәламәтлегебезне саклау, гаиләбез турында хәстәрлек күрү, якындагыларга һәм еракта булганнарга, аеруча дин кардәшләребезгә, алар аңа мохтаҗ булган вакытта ярдәм күрсәтү, аларның тормыш хәлләре белән кызыксыну, хаҗәтлеләрен кайгырту, хокукларын яклау кебек бурычларыбыз - безнең Аллаһ коллары каршындагы бурычларыбыз, алар да безнең дини бурычларыбыз булып санала.

Намазны калдыру, ураза тотмау, фарыз гамәл булган хаҗ кылуны санга сукмау һ. б. гамәлләр мөселман булган кеше өчен Аллаһ каршындагы бурычларын үтәмәү һәм гөнаһ булып исәпләнә. Шулай ук кеше үтерү, башка кешенең мөлкәтенә кул сузу, аның намуслы исеменә кара ягу, гайбәт, ялган сөйләү, яла ягу кебек гамәлләр дә гөнаһ булып санала. Болар барысы да кешеләрнең Аллаһ биргән хокукларына кул сузу булып тора һәм Аллаһ коллары каршындагы бурычларны бозу буларак, зур гөнаһлар исемлегенә керә.

Хак мөэмин-мөселман булу өчен Аллаһ каршындагы һәм Аллаһ коллары каршындагы бурычларыңны төгәл үтәп барырга кирәк. Бу гамәлләрне башкару - дини күзлектән караганда да, дөньяви күзлектән караганда да, һәр мөэминнең бурычы булып тора һәм ул аларны үтәргә тиеш. Аллаһның Рәсүле (саләллаһу галәйһи вәссәләм) кемнәр каршында бурычларны үтәү кирәклеге турында болай дип әйткән: *"...Раббыңның да синдә хокукы бар, гаиләң әгъзаларыңның да синдә хокуклары бар. Шуңа күрә дә син үзеңдә хокуклары булганнарның барысының да хокуклары үтәлешен тәэмин итәргә тиешсең".*

Безгә йөкләнгән бу бурычларны үтәү, Аның колы буларак, Аллаһ каршындагы бурычларны үтәүдән башлана. Ә аннан соң үзүзең каршындагы бурычлар килә, ә аннан ары - үз туганнарың, якыннарың, күршеләрең, дин кардәшләрең, милләттәшләрең, ватандашларың һәм башка бар кешеләр каршындагы бурычлар үтәлергә тиеш.

Безнең бөек ислам динебездә бурычларны биш төркемгә бүлү кабул ителгән:

1) Аллаһ каршындагы бурычлар, ягъни Аллаһның синдә булган хокуклары;

2) үз-үзең каршындагы бурычлар;

3) гаилә әгъзаларың каршындагы бурычлар;

4) үз халкың, үз ватаның каршындагы бурычлар;

5) башка кешеләр каршындагы бурычлар, кешеләрнең берберсе каршындагы бурычлары.

Иң беренче чиратта, һәрбер кеше аны юктан Бар итүче каршындагы бурычларын үтәргә тиеш. Бу бурычлар икегә бүленә: Аны танып белү буенча бурычлар һәм Аның колы буларак кылган бурычлар. Бу турыда Коръәндә болай диелгән: **"Кеше илә җенне... мәгәр Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен генә халык кылдым"** ***("Зарият (Таратучы)" сүрәсе, 51:56).***

Болар - безнең Аллаһ каршындагы бурычларыбыз булды. Шулай итеп, кешеләр һәм җеннәрнең яратылуының һәм бар булуның төп максаты - Аллаһ колы булу, Аңа гыйбадәт кылу.

Кайбер мөфәссир галимнәр, аятьтә кулланылган "гыйбадәт кылу" сүзләрен "танып белү" дип аңларга кирәк, диләр. Ә бу исә: "Аңа гыйбадәт кылучыны танып белү өчен яралтылганнар" дигәнне аңлата. Аның мәгънәсе болай булачак: "Минем хөкемнәремне башкарып, Миңа гыйбадәт кылырлар һәм Минем колларым булырлар".

Алда әйтелгәннәр буенча, кешенең иң беренче чираттагы бурычы - Аллаһны танып белү, Аңа гыйбадәт кылу һәм Аның колы булу.

Шуны һәрвакыт истә тотарга кирәк: Иң Кодрәтле Аллаһы Тәгаләнең беркемгә дә бәйлелеге юк, Аның гыйбадәт кылуыбызда да хаҗәте юк. Киресенчә, кешеләрнең Аңа гыйбадәт кылуда хаҗәтлекләре бар. Кешеләрнең тормышы, яшәеше, шатлык һәм кайгылары Аңа дөрес гыйбадәт кылуга бәйле.

Аллаһ шулкадәр Рәхимле һәм Шәфкатьле ки, Ул кимчелекләр белән тулы гыйбадәтләребезне кабул итә, алар өчен безгә күп нигъмәтләрен бирә. Шулай булмаганда, безнең кече һәм зур гамәлләребезнең, гыйбадәт кылуларыбызның нинди мәгънәсе булыр иде?

"Мәснәви" китабында язылганча, гыйбадәт кылуларыбызны чүл халкы китергән кечкенә генә бүләкләр белән чагыштырып булыр иде. Ә анда шундый бер хикәят бәян ителгән: *"Гомере буе чүлдә яшәгән бер гарәп, картаймыш көнендә бик фәкыйрьләнә һәм мохтаҗлыкта яши башлый. Алар хатыны белән бу хәлдән чыгу юлын эзләргә керешә. Моның бердәнбер юлы - Багдадка барып, андагы солтаннан ярдәм сорау була. Алар Багдадка барырга җыеналар. Чүл халкы өчен иң кыйммәтле әйбер - су, Багдад шәһәре дә чүлдә урнашкандыр, андагы халык та суга тилмерәдер, дип уйлап, алар солтанга бүләккә бер чүлмәк яңгыр суы алырга булалар.*

*Шулай итеп, бу гарәп бер чүлмәк су алып, Багдадка китә. Бик күп көннәрдән соң ул бу шәһәргә барып җитә. Сарайга килгәч, солтанның ярдәмчеләре аны каршы ала, хәлен белешә, кунакчыллык күрсәтеп, аның йөзенә алсу су сибә.*

*Бу гарәп болай ди: "Минем менә бу бүләгемне солтанга кертеп бирегез. Монда төче су. Без аны яңгыр яуганда җыйдык. Безне фәкыйрьлек тырнакларыннан йолып калыгыз".*

*Солтанның ярдәмчеләре аның ихлас күңелдән әйтелгән бу сүзләренә елмаеп куялар. Шуңа да карамастан, аның бу бүләген солтанга кертеп тапшыралар. Солтан бүләкне шатланып кабул итә һәм аңа җавап итеп, бу чүлмәкне алтын белән тутырып чыгара. Аннан тыш, ул аңа кыйммәтле киемнәр һәм башка бүләкләр дә тапшыра, шулай итеп, аны фәкыйрьлектән йолып кала. Шуннан соң солтан үзенең хезмәтчеләренә болай ди: "Бу бәдәви гарәп чүл буйлап барганда юлда авырлыкларга дучар булган. Аны Тигр елгасы буенча корабта кайтарып җибәрегез". Солтанның хезмәтчеләре, аның боерыгын тыңлап, корабка утыртырга дип, бәдәвине Тигр елгасы буена алып киләләр. Ул үз гомерендә беренче тапкыр дөньяда шундый зур суны күрә, моңарчы андый зур сулар, елгалар булуын күз алдына да китерә алмаган була. Гаҗәпләнүеннән, ул аңа карап сәҗдә кыла һәм аптыравыннан болай ди: "Нинди юмарт бу падишаһ! Күпме бүләкләр тарата ул! Шулкадәр дә күп суга, бетмәс-төкәнмәс сулы зур елгага ия була торып та, минем тыйнак кына шул бүләгемне - яңгыр суы җыелган бер чүлмәк суымны кабул итеп алды!"*

Безнең Аллаһка кылган бар гыйбадәтләребез дә бәдәви бүләк итеп биргән шул бер чүлмәк су кебек кенә. Бер шик тә юк ки, Аллаһы Тәгалә аларны Үзенең рәхим-шәфкатен күрсәтеп кабул итә. Ә аңа җавап итеп Ул безгә Үзенең күпме нигъмәтләрен бүләк итә. Кызганыч ки, рәхмәтсез кайбер кешеләр Аллаһы Тәгаләнең бу рәхимшәфкатьләренең бар зурлыгын тулысынча аңлап бетерә алмый. Алар үзләренең җитешсезлекләр белән тулы гыйбадәтләрен бик зур эш дип кабул итә.

### ҮЗ-ҮЗЕБЕЗ КАРШЫНДАГЫ БУРЫЧЛАРЫБЫЗ

Безнең үз-үзебез каршындагы бурычыбыз булып, иң беренче чиратта, үз тормышыбызны саклау һәм аны алга таба үстерү тора. Димәк, үз тормышыңны, үз саулыгыңны саклау - дини хөкем булып исәпләнә. Коръәни-Кәримдә бу турыда Аллаһы Тәгалә менә ни әйтә:

**"Аллаһ ризалыгы өчен Ул күрсәткән урыннарга малларыгыздан сәдака бирегез! Дәхи изгелек итегез, Аллаһ изгеләрне сөя"** ***("Бәкара (Сыер)" сүрәсе, 2/195).***

Кешенең җаннан һәм тәннән торуы аркасында, аның үз-үзе алдындагы бурычлары җан алдындагы һәм тән алдындагы бурычларга бүленә.

Безнең җан алдындагы бурычларыбыз - үзеңне рухи яктан көчле итеп тәрбияләү һәм үстерү. Рухи көчләрне, гакылны, ихтыярны тәрбияләү һәм үстерү. Моның өчен кешегә файдалы һәм яхшы рухи чыганаклар кулланырга, рухи бозыклыклардан читтә торырга тырышу лазем.

Тәнебез каршындагы бурычларга килгән вакытта, безнең динебез җанны гына түгел, тәнне дә сакларга һәм үстерергә куша. Шуңа күрә дә безгә алкоголь (исерткеч эчемлекләр) куллану, тәмәке тарту кебек начар гадәтләрдән баш тартырга кирәк. Алар тәнне зәгыйфьләндерә, саулыкны кимětә. Гигиена таләпләрен үтәү, чиста-пакь итеп киенеп йөрү, йогышлы авырулардан саклану шулай ук мөһим.

Аллаһның Рәсүле (салләллаһу галәйһи вәссәләм) болай дигән: *"Хисап көнендә шул өч сорауга җавап бирми торып, кеше азат ителмәс:*

*1.Үз тормышыңны ничек һәм кайда уткәрдең?*

*2.Үз гамәлләреңне нинди максатларда башкардың?*

*3.Үз мал-мөлкәтеңә ничек ия булдың һәм аны нинди максатларда тоттың?"*

### ГАИЛӘ ӘГЪЗАЛАРЫ КАРШЫНДАГЫ БУРЫЧЛАРЫБЫЗ

Безнең динебез һәр гаилә әгъзасына аерым бер бурычлар йөкли. Гаилә ул - үзе бер җәмгыять, кеше анда үсә, шәхес булып формалаша. Гаиләдәге әти-әни, балалар һәм башкалар - шул кечкенә генә бер җәмгыятьнең тулы хокуклы әгъзалары.

Иң башта ата-аналарның балалары каршындагы бурычларына тукталып китик. Ата-аналарның үз балалары каршындагы бурычлары турында шуны әйтергә була: ата-аналар үз балаларын җәмгыятьнең лаеклы әгъзалары, үз халкына һәм хәтта бар кешелеккә файда китерә торган шәхесләр итеп тәрбияләп үстерергә тиеш.

Әнәс ибне Мәликтән (радыйаллаһу ганһү) Аллаһ Рәсүленең (салләллаһу галәйһи вәссәләм) түбәндәге сүзләрен җиткерәләр: *"Балаларыгызга карата юмарт булыгыз, аларны яхшылап тәрбияләгез һәм өйрәтегез"* *(Ибне Мәҗәһ Сүнәне, 1211).*

Ата-аналар, балаларына җиде яшь тулганчы, аларның сәламәтлеге турында аеруча нык кайгыртырга һәм аларга үрнәк булырга тиеш. Җиде яше тулгач, балага белем һәм әхлак тәрбиясе бирүгә зуррак игътибар ителә. Ә аннары аңа ниндидер һөнәр (белгечлек) бирү өстендә эшләргә, әгәр дә моңа сәләте булса, аны сәнгатьнең ниндидер бер тармагына тартырга кирәк. Балага тормышта аякка басарга, гаилә корырга, үз йортын булдырырга ярдәм иту дә зарур.

Балаларның ата-аналары каршындагы бурычларына килгәндә исә, алар шулкадәр күп, хәтта санап та бетерергә мөмкин түгел. Аллаһ Рәсүленең (салләллаһу галәйһи вәссәләм) хәдисләренең берсендә әйтелгән: *"Бала бервакытта да атасы биргәннәрне түләп бетерә алмаячак. Хәтта аның әтисе кол булып, ул аны сатып алып иректә итсә дә"* *(Тирмизи, 1971 нче хәдис).*

Аллаһның Рәсүле (салләллаһу галәйһи вәссәләм): "Баланың әнисе каршындагы бурычлары әтисе каршындагы бурычларына караганда күбрәк", - дип басым ясап әйтә.

Балалар ата-аналарына яхшы сүзләр генә әйтергә, аларга карата игелекле гамәлләр генә эшләргә, аларга хәтта "уф" дип тә әйтмәскә, аларның кәефләрен төшермәскә, аларның күңелләрен күтәрә торган әйберләр генә сөйләргә тиеш. Боларның барысы да - Раббыбызның хөкемнәре. Коръәни-Кәримдә Аллаһы Тәгалә болай ди: **"Аллаһ хөкем итте вә әмер бирде, фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кылырга һәм ата-анага изгелек итәргә. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсә, син аларга "уф" та димә вә каһәрләмә, кәефләрен җибәрмә, бәлки аларга**

# БУРЫЧЛАРЫ ТУРЫНДА

**һәрвакыт йомшак вә мөлаем сүзләр генә сөйлә!" *("Бәни Исраил (Ягъкуб балалары)" сүрәсе, 17/23).***

Туганнар каршындагы бурычларны да игътибарсыз калдырырга ярамый. Өлкәннәрне хөрмәт итү, кечкенәләргә карата мәрхәмәтле һәм ярдәмчел булу - динебез хөкемнәре.

Үз якыннарыңа карата да яхшы мөнәсәбәттә булу зарур. Аларны хөрмәт итү, алар турында кайгырту, аларга ярдәм күрсәтү - аларның никадәр якын булуына карап башкарылырга тиеш.

Күршеләр каршындагы бурычларга килгәндә исә, ул да мөһим бурычларның берсе булып тора. Ибне Гомәр һәм Гайшә (радыйаллаһу ганһүмә) җиткергән риваять буенча, Аллаһның Рәсүле (саләллаһу галәйһи вәссәләм) болай дигән: *"Җәбраил миңа күршемнең хокуклары турында бертуктаусыз сөйләде. Мин хәтта күршемне мирасчым итәргә җыенамы икән әллә ул дип тә уйлап куйдым" (Мөслим. Китабел-бирр вәс-сыйлә вәл-әдәб. - Том 8/94. - 140-141 нче хәдисләр).*

Икенче бер хәдисендә Аллаһның Рәсүле (саләллаһу галәйһи вәссәләм) болай ди: *"Аларга зыян китермәячәгенә инанмаган кешенең күршеләре камил мөселман булмас" (Рияду Салихин. - Том I. - 303 нче хәдис).*

Аллаһның Рәсүле (саләллаһу галәйһи вәссәләм) үзенең "Хушлашу вәгазендә", мөселманнарга мөрәҗәгать итеп, бик тә әһәмиятле сүзләр әйтә: *"Ий кешеләр! Сезнең хатыннарыгыз каршында бурычларыгыз бар. Сез аларга карата яхшы мөнәсәбәттә булырга тиеш. Ә хатыннар ирләренең аларга карата булган хокукларына игътибарлы булырга тиеш. Бер мөэмин икенчесенә - туган. Бер мөэминнең милке икенчесе өчен - хәрам (ул аны үзе биргән очракларны исәпләмәгәндә). Мин сезгә тиешле дини хөкемнәрне китердем һәм сезгә, сез аларга тәкълид итсен өчен, ике әйбер калдырдым: аларның беренчесе - Коръәни-Кәрим, икенчесе - минем Сөннәтем".*

Бурычлар Аллаһ каршындагы бурычларга һәм Аның колларына каршындагы бурычларга бүленә, дидек. Әгәр дә: "Аларның кайсысы беренчел әһәмияткә ия?" - дисәгез, бу бурычларның икесе дә бик мөһим. Кайвакыт кешеләр каршындагы бурычлар әһәмиятлерәк тә булып тора. Чөнки Аллаһ Рәхимле вә Гафу итүче, әгәр безнең Аллаһка кылган гамәлләребездә җитешсезлекләр булса, без Хисап көнендә Аның ярлыкавына өмет баглый алабыз. Кешеләрдә рәхимлелек һәм гафу итүчәнлек сыйфатлары Аллаһныкына караганда күпкә азрак икәнлеген исәпкә алып, безгә аларның хокукларын бозудан читтә торырга тырышырга һәм алар алдында бурычлы булып калудан сак булырга кирәк.

Аллаһның Рәсүле (саләллаһу галәйһи вәссәләм) бурычлары белән вафат булган бер сәхабәсе өчен җеназаны да үзе укымаган, аны укуны үзенең икенче бер сәхабәсенә тапшырган. Сәхабәләренең берсе үлгән кешенең бурычын кайтарганнан соң да Аллаһның Рәсүле (саләллаһу галәйһи вәссәләм) аның өчен җеназа укымаган (А.Х. Аксеки. Олы илмихәл. - Б. 198).

Монда игътибарга лаек бер урын бар: Аллаһ колларының хокуклары исламда бик югары бәяләнә.

Әбү Һурайра (радыйаллаһу ганһү) шушы хәдисне тапшыра. *"Аллаһ Рәсүле (саләллаһу галәйһи вәссәләм) бервакыт үз сәхабәләреннән: "Кемнең банкрот булуы сезгә билгелеме?" - дип сораган. Сәхабәләр: "Ул - акчасы да, мөлкәте дә булмаган кеше", - дип җавап биргән. Аларның бу сүзләреннән соң, Аллаһның Рәсүле (саләллаһу галәйһи вәссәләм) болай дип әйткән: "Кем укыган намазлары, тоткан уразалары, биргән зәкятләре, тик шул ук вакытта, кемдер башка берәүне ачуланып сүккән, аңа кара яккан, икенче берәүнең мөлкәтен канунсыз ашаган [үзләштергән], өченче берәүнең канын түккән яки кемнедер кыйнаган гамәлләре белән Хисап көненә килә - минем өммәтемдә шул кеше банкроттыр. Кылган изге гамәлләрен ул, аларны җәберсеткән өчен, үзе рәнҗеткән кешеләргә бирергә тиеш булачак. Әгәр дә аның игелекле эшләре бу кешеләргә әҗерен түләгәнче бетсә, ул кешеләрнең гөнаһлары аңа күчереләчәк, һәм ул шул кешеләрнең гөнаһлары өчен җәһәннәм утына ташланачак" (Мөслим. Китабел-бирр. - Т. 8/59).*



Аллаһ Рәсүленең (саләллаһу галәйһи вәссәләм) әлеге сүзләренә дә зур игътибар бирергә кирәк: *"Хисап көнендә бар хокуклар да мотлак рәвештә торгызылачак. Хәтта мөгезсез сарык та мөгезле сарыктан үз әҗерен алачак" (Мөслим. Китабел-бирр. - Т. 8/60).*

*"Әгәр кем дә булса икенче берәүнең бер уч җирен булса да рөхсәтсез алса, аңа алганы кадәр җиде тапкыр арттырып түләү йөкләтеләчәк" (Рияду салихин. - Т. 1/209).*

Аллаһ Рәсүле (саләллаһу галәйһи вәссәләм) башкаларга киңәш иткән гамәлләрне шәхсән үзе дә башкара торган булган.

Һиҗринең унберенче елында, авыру сәбәпле көчен югалтканда, бер кулы белән абыйсы Габбас улы Фазылга, икенче кулы белән абыйсы Әбү Талип (радыйаллаһу ганһүмә) улы Галигә таянып, Аллаһның Рәсүле (саләллаһу галәйһи вәссәләм) мәчеткә килә. Мәчеттә ул мөнбәргә күтәрелә. Аллаһы Тәгаләгә мактаулар җиткергәч, ул болай ди: *"Ий кешеләр, әгәр дә мин кемнең дә булса аркасына суккан булсам, менә минем аркам - аның өчен җавап итеп, килсен дә минем аркага суксын. Әгәр дә мин кемгә дә булса бурычлы булсам, минем мөлкәт каршыгызда - үзенә тиешлесен барып алсын".* Аннары мөнбәрдән төшеп өйлә намазын укыган. Намазын укып бетергәч, мөнбәргә менеп, тагын шул ук сүзләрне кабатлаган. Шулвакыт бер кеше Пәйгамбәрнең (саләллаһу галәйһи вәссәләм) аңа өч дирһәм бурычы барлыгы турында әйткән. Бу бурыч аңа шунда ук кайтарып бирелгән (Кыйссасел-әнбия. - Т. 1/235-236).

Икенче бер риваятьтә, икенче бер кеше, бер сугыш вакытында Аллаһ Рәсүленең (саләллаһу галәйһи вәссәләм) бер хайванга сугам дип, аңа тидерә алмыйча, ялгыш шул кешегә камчысы белән сугуы турында әйтелә. Хәзер инде ул моның өчен җавап бирергә теләвен белдергән. Аллаһның Рәсүле (саләллаһу галәйһи вәссәләм) өеннән шул камчыны табып китерергә һәм ул кешегә, Пәйгамбәр (саләллаһу галәйһи вәссәләм) аңа сугыш вакытында ничек итеп суккан булса, шулай ук итеп үзенең аркасына сугарга кушкан. Ләкин ул кеше сугыш вакытында киемен салып ташлаган, аркасының ачык булуы, шуның өчен Аллаһ Рәсүленең (саләллаһу галәйһи вәссәләм) шәрә аркасына сугарга тиешлеге, шул вакытта гына тиешле әҗерен алачагы турында әйткән. Аллаһның Рәсүле (саләллаһу галәйһи вәссәләм) күлмәген җилкәсенә кадәр күтәргән дә, аркасын ачып, шул ачык тәнгә сугарга кушкан. Тик теге кеше Аллаһ Рәсүленең (саләллаһу галәйһи вәссәләм) аркасында, ике калак сөяге арасында, пәйгамбәрлек мөһерен күреп, кулындагы камчысын ташлаган да, шул мөһерне иелеп үпкән. Аннары ул Аллаһ Рәсүленең (саләллаһу галәйһи вәссәләм) күлмәген кире төшереп, болай дип әйткән: "Мин әҗерен кайтарырга, сиңа сугарга теләмәгән идем, аркаңдагы шул мөһерне генә үбәргә ниятләгән идем. Мине гафу итәрсең дигән өметтәмен".

### ХАЛКЫБЫЗ ҺӘМ ДӘҮЛӘТЕБЕЗ КАРШЫНДАГЫ БУРЫЧЛАР

Бу бурычларны башкача гражданлык бурычлары дип тә атыйлар. Болар - гражданнарның үз халкы каршында, дәүләте, үзе яшәгән илдәге дәүләт хезмәткәрләре каршындагы бурычлары. Дәүләт системасында эшләүче кешеләр илнең бар халкын да яратырга, алар мәнфәгатьләрендә хезмәт куярга; илнең гражданнары дәүләт структурасы эше белән канәгать булсын һәм үзләренең тормыш дәрәҗәләрен күтәрә алсын өчен тырышлык куярга тиеш.

Шулай итеп, дәүләт оешмаларында эшләүчеләрнең гражданнар каршындагы бурычлары да мөһим. Алар ил гражданнарының хокукларын, аларның вөҗдан пакьлеген якларга, илдә тәртип сакларга тиеш.

### КЕШЕЛӘРНЕҢ БЕР-БЕРСЕ КАРШЫНДАГЫ БУРЫЧЛАРЫ

Аларның мөселман булу-булмавына карамастан, кешеләрнең бер-берләре каршында бурычлары бар. Аларны гомумкешелек бурычлары дип атарга була.

Аллаһы Тәгалә безгә болай ди: **"Тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә һәр эштә гадел булырга һәм дин вә мөселманнар файдасына яхшы эшләр кылырга вә якын кардәшләрнең хакын үтәргә боера вә Аллаһ сезне тыя фәхеш-хәрәм эшләрдән вә шәригать белән сабит булмаган бидгать гамәлләрдән һәм зуреап хактан качудан, хаксыз золым итүдән. Аллаһ сезне вәгазьли, шаять, вәгазьләнерсез!" *("Нәхел (Бал кортлары)" сүрәсе, 16/90).***

Бу темага кагылып, Аллаһның Рәсүле (саләллаһу галәйһи вәссәләм) болай дип әйтә: *"Үзең өчен нәрсәне яратсаң, якының өчен дә шуны ук ярат, үзеңә теләмәгән бер нәрсәне дә якыныңа теләмә" (Бохари. Китабел-иман. - Т. 1/13).*

Әлеге аять һәм хәдис, үзебезнең шәхси һәм җәмәгать каршындагы бурычларыбызны билгеләгәндә, безнең тугры ярдәмчеләребез булып тора. Безгә әйтелгәнчә, кешеләрнең тормышына һәм ирегенә, мөлкәтенә, вөҗданына хөрмәт вә игътибар күрсәтү - безнең өчен мәҗбүри эш булып исәпләнә.

Шул ук вакытта, башка кешеләргә хөрмәт күрсәтү һәм сөю хисе белән карау, аларга ярдәм итү, алар өчен җаныңны фида кылу (корбан итү) кебек эшләрне без бернинди мәҗбүр итүләрсез дә эшли алабыз.

Башка кешеләрнең тормышына, ирегенә, вөҗданына игътибарлы булган кеше башкаларның да аның үз тормышына, ирегенә, вөҗданына игътибар белән карауларына лаек.

Аллаһы Тәгалә безне хак һәм туры юлдан аермасын. Безне Аллаһка Аның колларына мөнәсәбәтле хокукларга һәм бурычларга игътибарлы булучылардан әйләсә иде.

Амин!

Иҗтиһад итү - бездән, уңыш - Аллаһтан.

***Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН***

# "Хатын-кызлар - динебезне буыннан-буынга саклап килүчеләр"

**Мөселман хатын-кызларының беренче корылтае уздырылуга 9 ел үткәннән соң, ниһаять, "Казан" милли мәдәният үзәгендә Татарстан Мөселман хатын-кызлары иҗтимагый берлегенең II Республикакүләм корылтае үткәрелде. "Мәрхәмәтлелек һәм тынычлык сөюче хатын-кызлар" исеме астында узучы форумга республикабызның төрле районнарыннан 300 дән артык мөслимә җыелды, Башкортстан һәм Мордовия республикаларыннан да делегатлар бар иде.**




Татарстан Җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте карамагында уздырылучы әлеге җыелышның максаты - киләчәк буынны тәрбияләүдә, рухи кыйммәтләргә хөрмәт уятуда мөслимәләрне берләштерү, сәламәт яшәү рәвешен, гаилә кыйммәтләрен пропагандалау, ТР Мөселман хатын-кызлары иҗтимагый берлегенең республика районнарындагы филиаллары эшен активлаштыру.

Корылтайда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, ТР Дәүләт Советы депутаты Фәрит Мифтахов, Казан шәһәре башкарма комитетының телләрне үстерү һәм иҗтимагый оешмалар белән багланышлар бүлеге башлыгы Ирек Арсланов, Казан шәһәре мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдинов, Татарстан Мөселман хатын-кызлары иҗтимагый берлеге рәисе Наилә Җиһаншина, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты аппараты җитәкчесе Миләүшә Гомәрова, җәмәгать эшлеклесе, язучы Фәүзия Бәйрәмова, һ.б. махсус чакырылган кунаклар һәм республикабызның актив мөслимәләре катнашты.

Чараны Камил хәзрәт Сәмигуллин Коръән аятьләрен укып ачып җибәрде. Хатын-кызларның җәмгыять яшәешендә тоткан, аның рухи үсешендә башкарган мөһим урынын билгеләп ул: "Сезнең фикерләрегез, тәкъдимнәрегез безнең өчен бик мөһим, чөнки дингә күбебез хатын-кызлар аша килә, күркәм нәсыйхәтләрне дә күпне күргән әбиләребездән, абыстайлардан ишетәбез. Мондый җыелышлар, мәсьәләләрне уртага салып сөйләшүләр - кирәкле гамәл. Бердәм булган очракта гына максатларыбызга ирешә алачакбыз. Бергәләп өммәтебез өчен тырышырга, эшләргә насыйп итсен!" - диде.

Мансур хәзрәт Җәләлетдинов үз чыгышында динебезне үстерүдә үз өлешен керткән мөслимәләрне искә алды: "Элек мондый җыелышлар үткәрелми иде. 80 нче елларда динне Мәрҗани мәчетенең подвалында өйрәнсәк, 90 нчы елларда Рәшидә абыстай Исхакый Нурулла мәчетендә дин сабаклары укыта башлады. Мөхлисә Бубый, Рәшидә Исхакый, Әлмира Әдиятуллина, Фәүзия Бәйрәмова, Наилә Җиһаншина кебек мөслимәләребезнең эшчәнлеге һәм тырышлыгы нәтиҗәсендә динебез алга китте, шушындый зур җыеннар үткәрелә башлады. Алар динебезне буыннан-буынга саклап килүчеләр, үстерүчеләр. Аллага шөкер, динебез көчәйде, мәчетләребез көннән-көн арта: Казанда 57 мәчет эшли, 11 мәхәллә төзелеш юлында".

Корылтайның рәсми ачылышы тәмамланганнан соң, ТР Мөслимәләр берлеге рәисе Наилә Җиһаншина хатын-кызлар оешмасының эшчәнлек нәтиҗәләре һәм киләчәккә планнары белән таныштырып үтте. Алга куелган максатлар арасында интернет челтәрендәге әшәкелек, әдәпсезлеккә каршы көрәш, мәктәпләрдә әхлак дәресләрен кертү, мөселман хатын-кызларының Язучылар берлеген оештыру, "Мөселман хатын-кызлары дөньясы" исемле телепроект булдыру һ.б. да бар.

"Мөхәммәдия" мәдрәсәсе мөгаллимәсе Флера Ханнанова фикеренчә, әхлак, дин белән баланы кечкенәдән үк таныштырырга кирәк. "Мәктәптә укытыла торган татар әдәбияты әсәрләрендә татар хатын-кызының нинди булырга тиешлеге ачык чагыла. Әдәбиятны белми торып, әхлакка өйрәнеп булмый!" - дип саный ул.

Корылтайда яңгыраган "динебез үсә", "зур эшләр эшләнә" кебек фикерләргә каршы Фәүзия Бәйрәмова чынбарлыкка туры карарга чакырды: "Дин бар дисәләр дә, бәхетебез китек: халкыбызның 80-85 проценты үзен мөселман дип саный, әмма намаз укымый. Шуның өстенә гөнаһ "мыж"лап тора: зина, риба һ.б. Дәгъвәт җитми, ә дәгъвәт ул - без үзебез, үз-үзебезне тотышыбыз. Яхшылык эшләргә, башкаларга үрнәк булырга, ярдәм итәргә, милләтнең "башыннан сыйпарга" кирәк!"

Корылтайда катнашкан ТҖ МДНнең "Хәләл" комитеты белгече Ирек Җиһаншинның чыгышы да зур игътибарга лаек. "Күп ата-аналар балалар бакчаларында, мәктәпләрдә балаларының хәләл ризыклар белән туклануын телиләр. Бу мөмкин эш. Бары бакча яисә мәктәп җитәкчелегенә, хәләл ризык белән тәэмин итсәгез иде, дип гариза язарга кирәк. Аннан инде без җитәкчелек белән бу эшне хәл итә башлыйбыз. Башкалабызның 66 балалар оешмасында хәләл ризык ашатыла", - диде белгеч.



Чыгышлар тәмамланганнан соң, Татарстан Мөселман хатын-кызларының II корылтае мәктәпләрдә мөслимәләргә яулык бәйләп йөрүне тыймауны сорап, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгына, мөселман хатын-кызларының эшкә урнашканда һәм эш урыннарында хокуклары бозылмауны тәэмин итүне сорап, ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына мөрәҗәгать итәргә; "ТНВ" каналында хатын-кызлар, гаилә, тәрбия мәсьәләләренә багышланган тапшырулар булдырырга; Солдат аналары берлеге оештырырга, Россия Саклану министрлыгына мөселман аналар исеменнән мөселман солдатлар турында статистик исәпләүләр үткәрүен һәм Россия армиясендә мөселман руханилары институты булдыруны сорап мөрәҗәгать итәргә дигән карарга килделәр. Әлеге карарлар нәтиҗәсендә бертавыштан II корылтайның резолюциясе кабул ителде.

## "ОСТАБИКӘ" ИСЕМЕНӘ КАЙСЫ МӨСЛИМӘ ЛАЕК?

"Казан" милли-мәдәният үзәгендә "Остабикә" конкурсына йомгак ясалды. Әлеге конкурс республикабызда берничә ай элек игълан ителгән иде. Татарстанның төрле районнарында үткәрелгән "Зирәк хатын" конкурсында җиңү яулаган мөслимәләр өчен "Остабикә" - бәйгенең финал өлеше иде.

Бәйге ТР Мөслимәләр берлегенең II корылтае кысаларында уздырылды. Татарстан Җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, Татарстан Мөселман хатын-кызлары иҗтимагый берлеге, Ислам мәдәниятенә, үсешенә, мәгарифенә ярдәм итү фонды булышлыгында оештырылган бәйгенең максаты - сәләтле мөслимәләрне, "Остабикә" мәртәбәле исемен йөртергә лаеклыларны барлау, җәмгыять тормышында актив эш алып баручы мөслимәләрне хөрмәтләү һәм аларның эшен киң җәмәгатьчелеккә күрсәтү.

Конкурста Татарстанның 16 районыннан җыелган сәләтле һәм үзен күрсәтә белгән мөслимәләр катнашты. Конкурс шарты буенча, алар, билгеләнгән кыска вакыт эчендә, үзләре, районнары белән таныштырырга, аш-суга һәм кул эшләренә осталыкларын күрсәтергә тиеш иде.

Жюрида утыручы мөслимә-активистларыбызга (мәгърифәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Сәйдә Аппакова, язучы Фәүзия Бәйрәмова, "Мөслимә" хатын-кызлар иҗтимагый оешмасы рәисе Әлмира Әдиятуллина һ.б.) җиңүчене билгеләү кыен булгандыр. Ни өчен дигәндә, конкурста катнашучыларның һәрберсе үзенә күрә кызыклы һәм үзенчәлекле чыгышлар әзерләп килгән иде. Беренче өлештә, алар презентация һәм тел осталыгы ярдәмендә районнарындагы мөслимәләр оешмасы эшчәнлеге, гаиләләре белән таныштырдылар. Аннары исә конкурсантлар жюри әгъзаларын үзләре пешереп алып килгән ризыклардан авыз иттерделәр. Шуны әйтергә кирәк, әлеге ризык төрләре буенча да мөслимәләрнең кайсы районнан икәнен билгеләргә була иде. Һәр районның үзенә генә хас, танылган ризыгы һәм рецепты бар икән. Татар милли ризыгы саналган чәк-чәкнең генә дә әллә никадәр пешерү сере барлыгы ачыкланды. Катнашучылар әлеге серләр белән бик теләп уртаклашты.

Мөслимәләр буш вакытларын заяга уздырмыйлар икән. Яратып башкара торган шөгыль нәтиҗәсендә барлыкка килгән кул эшләнмәләре арасында нәрсәләр генә юк! Бәйләгән башмаклар, чиккән мендәр тышлары дисеңме, тукыган келәмнәр, ташка буяп язылган догалар, челтәрдән тегелгән кулчатырлар һ.б. - катнашучыларның кул эшләренә осталыклары, мөгаен, җиңүчене билгеләүдә хәлиткеч рольне уйнагандыр.

Хәтта катнашучыларның киемнәрен дә игътибарсыз калдырмады жюри. Алар өстенлекне татар милли киеменнән чыгыш ясаган хатын-кызларга бирде. Нәтиҗәдә, республикабызның иң оста һәм зирәк мөслимәсе исеме өч хатын-кызга бирелде: Нурлат районыннан Гүзәл Җамалиева, Мөслимнән Фәридә Шәрәфиева һәм Арчадан Гөлшат Гыйниятуллина бәйгенең җиңүчеләре дип табылды. Аларга диплом, көнкүреш техникасы, хәләл табигый косметика җыелмалары тапшырылды. Башка катнашучылар да буш кул белән китмәде: аларга да грамоталар һәм кыйммәтле бүләкләр бирелде.

***Сәхифәне КФУ студенты Мәрьям АБДУЛЛИНА әзерләде***

# "ФӘНИЯБИКӘ" МӘДРӘСӘСЕ

"...Аллаһы Тәгалә ул һәрнәрсәне белүче, савабын тар кылмас..." *("Бәкара (Сыер)" сүрәсе, 215 нче аять)*

## АВЫЛЫБЫЗ ТАРИХЫННАН

Ихлас, тәвәккәл өч мөселман гаиләсе, көчләп чукындырулардан качып, Казаннан Әби патша юлы буйлап Себергә таба юл тоткан. Кара урманнар кичкәндә, тыныч чишмәле аланнар, ярдәмчел мари, удмурт халкы яшәгән авыллар очрый. 1553 нче елның язы җитә. Торак урын әзерләргә, гаиләне ризык белән тәэмин итәргә кирәк. Белемле булганнар, укый-яза белгәннәр. Җирле халык белән дус-тату булып гаиләләр корганнар, ислам динен тараткканнар, гарәпчә укыргаязарга өйрәткәннәр. "Тирә-як авылларда өркеп качкан өч кеше" дигән мәгънәне алып, авылның исеме Өркеш булып калган.

Тарихый вакыйгаларны 1960 нчы еллардагы укытучыбыз Зәкиҗан кызы Өммөхода апа дини вә дөньяви белемле Шәрәфетдин хәзрәтне мәктәпкә чакырып сөйләтә иде. (Йә Раббым, аларга догаларыбыз ирешсә иде). Көчләп, кызыктырып чукындыру килгәнче бу якларда ислам дине ныгып өлгергән.

Ул елларның истәлеге булып, өч керәшен авылы бар иде, икесе хәзер юк инде. Пугачёв восстаниесе вакытында Өркештән генә дә 200 ир чыгып китә.

XIX гасыр ахырында алпавыт Зайцев, авыл халкын яратып, мәчет салыр өчен төзү материаллары (такта, кадак, җиз, калай) бирә. Бу зур, матур мәчет Галәветдин бабай тыкрыгы каршында урнашкан була. Мәчет 1950 нче елга кадәр эшли. Мәчетне сүтүдә, манарасын төшерүдә катнашканнарның язмышы аяныч булды. Әлхәмдулиллаһ, аларның нәселләре килеп гафу үтенә, хәзерге мәчет төзелешендә катнаша. Аллаһы Сүбхәнәһү вә Тәгалә - Рәхимле, Гафу кылучы. Ә Галәветдин бабайга килгәндә, ул ветеринария фельдшеры һәм мулла була. 1937 нче елда Казанда атыла. Репрессия корбаннары исемлегенә эләгә.

## БЕРЕНЧЕ АЗАН

2001 нче елда Өркештә мәдрәсә ачылды. Аның түбәсендә Галәветдин бабайның хәләл җефете Мәсрүрә әби яшерен саклап калган ай тора. Авылыбызда кабат азан тавышы яңгырый башлады, мөселман дине турында гыйлем тарату, әдәп-әхлак тәрбияләү учагы барлыкка килде. Бу мәхәллә 2003 нче елдан Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләренең практика үтү базасы булып тора. Мәдрәсәдә кышкы һәм җәйге каникуллар вакытында балалар һәм яшьләр өчен дин дәресләре оештырыла. Җомга намазлары, рамазан айларында тәравихлар укытыла, ифтар мәҗлесләре үткәрелә.

## ҖӘЙЛӘҮ ЭШЛӘРЕ

Һәр җәйдә балалар өчен ике смена ислам җәйләве эшли. Ә 2005 нче елдан 1-16 нчы август көннәрендә дөньяви уку йортларында укучы туташлар өчен махсус җәйләү оештырыла. Унбиш көн дәвамында алар Коръән гыйлеме, ислам дине нигезләре, шәригать канунннары буенча дәресләр ала. Быел, шулай ук, югары белемле, тәҗрибәле юристлар, журналистлар белән сорау-җавап кичәләре оештырылачак, табибләр практик дәресләр бирәчәк. Моннан тыш, көн дәвамында йога, цигун һәм башка системалар буенча күнегүләр ясау кертелгән.

Җәйләү эшчәнлегендә аерым урынны дәгъвәт эше алып тора. Ул үз эченә мөселман дине турында стенгазеталар чыгаруны, күрше авылларда исламга багышланган кичәләр уздыруны ала. Аларның төп темасы булып кешенең үз-үзенә карата әдәбе, сәламәтлек саклау, әдәп-әхлак тәрбияләү тора. Бу җәйләү эшендә Казан шәһәренең Гадел мәчете остазлары, Кукмара районы мөхтәсибәте, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе кызлары ярдәм итә. Мәдрәсәдә борынгы кульязмалар; төрле илләрдә, төрле елларда язылган

һәм басылган Коръән китаплары күргәзмәсе; зур китапханә; тарихый-көнкүреш музее бар. 2011 нче елдан әниләр-бәбиләр җәйләве дә эшли башлады.

## МӘХӘЛЛӘ ОЕШУ

Мәдрәсәне яратып, шәкертләр аны "Фәниябикә" мәдрәсәсе дип атады. Хәтта язучы-журналист Вәсилә Рәхимова шул исем язылган такта да кайтарып элде. Хәзерге вакытта куллпнылышта шул исем йөри. Әмма бу рәсми атама түгел. Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәлам яшәгән, беренче ислам дәүләте мәркәзе Мәдинә шәһәре һәм бу якларда ислам динен тараткан остазларга хөрмәт йөзеннән, 2009 нчы елда рәсми рәвештә Мәдинә мәхәлләсе оешты. Әлегәчә мәчет юк иде. Бары 2012 нче елда гына мәчет нигезе салынды. Бүгенге көндә төзелеш эшләре кайный.

## МӨСЕЛМАННАР ҖЫЕНЫ

Һәр елны җәйләүнең соңгы көнендә зурлап яшьләр җыены үткәрелә. Бәйрәм кысаларында спорт ярышлары, балалар һәм яшүсмерләр өчен уеннар, концерт программасы, дәрәҗәле кунаклар белән очрашу, сату-алу сәүдәсе оештырыла. Шулай ук борынгы китаплар, кульязмалар, тегү-чигү мирасына караган әйберләр, авыл тарихына багышланган күргәзмәләр эшли. Мөселманнарның әлеге бәйрәмендә Кукмара мөхтәсибәте, күрше авыллардан имамнар, абыстайлар, җирле авыл җитәкчеләре, мәктәп укытучылары, башкалабызның Гадел мәчете остазмөгаллимнәре катнаша. Бәйрәм көндезгә сәгать унда (10.00) башлана.

## КАЙТУ ЮЛЫ

Һәр елны 1 нче августта, сәгать иртәнге тугызынчы яртыда (8.30) җәйләүгә баручыларны Казан шәһәренең Гадел мәчете янында автобус көтә. (Адресы: **420059 Казан шәһәре, Оренбург тракты, 193 нче йорт, "Южная" тукталышы. Тел.: +7 (843) 269-50-37; +7 (84364) 3-05-83.) Алдан язылу өчен телефон: +7 (843) 269-03-05; +7-909-309-71-35; +7 (84364) 3-05-83.**

***Фәния ҖӘЛӘЛИЕВА,***
***Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә, Гадел мәчете мөгаллимәсе, җәйләүләрне оештыручы***

# "ИҢ МӨҺИМЕ – БАЛАЛАРНЫҢ ИМАНЛЫ БУЛЫП ҮСҮЕ"

**Казанның Гаилә мәчете каршындагы лагерьның кызлар һәм малайлар сменаларына 60 ар баланы кабул итәргә планлаштырылса да, анда 160 ка якын бала йөрде. Мөрәҗәгать итүчеләрне кире борырга кыенсындык, ди хәзрәтләр. Балаларның лагерьда узган һәр көне файдалы һәм кызыклы узарга тиеш - көн тәртибен дә алар әнә шуны күздә тотып төзеделәр.**



Россия ислам институты һәм "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе шәкертләре иртәнге якта балаларга Коръән, гакыйдә, әдәп-әхлак дәресләре укыттылар. Моннан тыш лагерьның һәр көне берәр тематикага багышланды. Татар мәдәнияте, гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре белән танышу көнендә, мәсәлән, кызлар Сабантуе уздырдылар: кашыкка йомырка куеп йөгерү, капчык киеп узышу, чүлмәк вату, таяк тартышып көч сынашу дисеңме - чыпчын Сабантуе инде!

Габдулла Кариев исемендәге Яшь тамашачылар театры артистлары Аманулланың "Суперсветофор" әсәре буенча әзерләнгән курчак театры спектаклен алып килгәннәр иде. Сәгатьтән артык барган тамашаны кызлар тын да алмый карап утырды. Ә малайлар исә театрга үзләре сәфәр кылды. Дөресрәге, аларны Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең (ЮХИДИ) Совет районы бүлекчәсе хезмәткәрләре "Әкият" курчак театрына алып бардылар. Инспекциянең укукыту үзәгендә булу, аларның музейлары белән танышу тизрәк руль артына утырырга хыялланган малайларга аеруча тәэсир итте, алар күз алдында үсеп киттеләр сыман.

Балаларга җәйге яллары вакытында исламча тәрбия һәм гыйлем бирүне күздә тоткан Гаилә мәчете коллективы максатына ирешкәндер, иншә Аллаһ. Лагерьның ябылышы тантанасында катнашкан һәркем моны үз күзләре белән күреп инана алды. Иң кечкенә "Йолдызчыклар" төркеме сабыйлары да биредә өйрәнгән Коръән сүрәләрен, догаларны яттан сөйләп сокландырды, балалар исламга багышланган шигырьләр дә сөйләделәр, нәшидләр дә җырладылар, гыйбрәтле тамашалар да күрсәттеләр. Татарстан мөфтие урынбасары, Гаилә мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин мәчет коллективы исеменнән шушы балаларны тәрбия кылган укытучы, тәрбияче апаларына, ашатканэчерткән пешерүчеләргә һәм балаларның үзләренә, аларның әти-әниләренә рәхмәт сүзләрен җиткерде. "Иң мөһиме - балаларның иманлы булып үсүе. Монда алган гыйлем һәм тәрбия алдагы тормышларының ачкычы булсын. Мәчет юлын беркайчан да онытмасыннар. Бирегә һәркемгә юл ачык", - дип ул килгән кунакларга сүз бирде. Балаларны "күптәнге дуслары" - ЮХИДИнең Совет районы бүлекчәсе хезмәткәрләре сәламләде. Тәртипле, тәрбияле булып үсүләрен һәм юл йөрү кагыйдәләрен беркайчан да бозмауларын теләп, алар балаларга юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтә торган китаплар, юл әлифбасы, буягыч әсбаплар бүләк иттеләр.

"Ә мин бу юлы буш кул белән генә килгәнмен, - диде Бөтенроссия "Татар гаиләсе" иҗтимагый фондыннан Миләүшә ханым Гайфуллина, һәм бу "ялгыш"ын киләсе юлы төзәтергә вәгъдә итте. - Гаилә мәчетендә барган тәрбия эшчәнлегенә сокланып утырдым. Балаларның динебезне дә, телебезне дә белүләре бик шатландыра. Вәгазь ана телендә укылганда җан белән җанның сөйләшүе кебек бит ул".

Соңыннан балаларга тәмтомнар тутырылган каплар таратылды, мәхәллә яшьләре аларны "татлы мамык" белән сыйлады.

***Мәрьямбану ХАФИЗ***

**ХАТЛАРЫГЫЗНЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ (Лобачевский ур., 6 нчы йорт) яисә *naubahar67@list.ru* адресы буенча җибәрә аласыз**

## КУНАК ХАКЫН ХАКЛАП КАЛЫЙК

Рамазан ае минем өчен инде менә ничә еллар тоташ бер бәйрәм булып уза иде. Көн дә ифтар, көн дә кунаклар, якын дуслар, кардәшләр... Әмма быел барысы да үзгәрде. Чит шәһәр... Яңа тормыш... Якын кешеләр, таныш йөзләр - барысы да туган шәһәремдә калды. Ә мин ялгызым тәрәзәдән карап утырам. Бераз кәефем күтәрелмәсме дип дусларыма шалтыраттым. Алар ифтар ашы үткәрәләр икән, мине дә чакыралар. Эх, бик барыр идем, ара якын түгел шул. Шулчак Индонезиядәге дустым исемә төште. Ул да туган жиреннән еракта, аңа да моңсудыр дип, хәл-әхвәл сорашып смс юлладым. Дустым исә, хәлләрем бик әйбәт, рамазанны кунактан кунакка йөреп уздырабыз, дип жавап кайтарды. Шул вакытта үземнең чит шәһәрдә ялгызлыктан һәм моңсулыктан интегүемне хәбәр иттем. Аның жавабы озак көттермәде. "Өйдә утырсаң шулай була ул, мәчеткә тәравих намазына бар. Анда кызлар күп йөри, танышырсыз, аралашып китәрсез", - дип жавап кайтарды. Жавап кырысрак иде, әмма минем өчен бер этәргеч булды. Утырып бераз елап алгач, тәһарәтләндем дә мәчеткә киттем.

Мәчеткә якынайган саен мин никтер бик нык дулкынлана башладым. Куркып кына ишекне ачып жибәрдем. Ул мизгелне беркайчан да оныта алмамдыр - мин икенче бер дөньяга килеп кергәндәй булдым. Хәзрәтнең тавышы бөтен мәчетне яңгыратып туп-туры йөрәгемә үтеп керде, хәтта тыным кысылды. Күз яшьләремне көчкә тыеп, баскычтан тиз-тиз өскә күтәрелдем. Менә бит мин эзләгән әйбер! Менә нәрсә житмәгән икән йөрәгемә! Тәравих намазы яңа гына башланган иде, мин дә ашыга-ашыга жәмәгатькә кушылдым. Кулларымны кыямда бәйләвем булды - күзләремнән мөлдерәп яшьләрем тәгәрәде. "Таптым бит, Раббым, Сине таптым бит! Күпме эзләдем мин Сине! Гафу ит мине! Гөнаһларым күптер, гафу ит!" Шул сүзләрне намаз беткәнче кабатладым. Күземә һичкем, һичнәрсә күренмәде. Раббың белән аралашудан да мөһимрәк нәрсә юк икән! Дөньяның бер ләззәте дә хошуг белән укылган намаз ләззәтенә җитмидер. Тел белән дә, каләм белән дә язып, анлатып булмый ул хисне, фәкать йөрәк белән генә тоеп була...

Шул халәттә ай буена намазымны укып, гөнаһларымнан арынып, Аллаһка якынаюымны сиздем. Укылган Корьән сүрәләре, хәзрәтләрнең үтемле вәгазьләре, әлбәттә, эзсез калмады. Менә бит рамазанның, тәравихларның хикмәте нәрсәдә! Ун яшемнән бирле ураза тотсам да, беренче рамазанымны 26 яшемдә генә таптым...

Әлбәттә, рамазан ул - бәйрәм, әмма кеше ифтарларга, кунактан-кунакка йөрү белән генә чикләнмичә, бар көчен рухи азык табуга юнәлтеп, үзенең җанын пакьләү өстендә эшләп, рухи яктан камилләшүгә омтылырга тиеш. Рамазан ул - Аллаһның ризалыгын алу мөмкинчелеге тудыра торган бәйрәм. Ул дөнья мәшәкатьләреннән арынып, көндезләрен уразада булып, кичләрен, төннәрен гамәл-гыйбадәттә үткәреп, Аллаһка якынаю юлларын эзләү өчен зур форсат. Рамазан ул - елга бер тапкыр килә торган кадерле кунак. Ә кунакның хакы бар. Гафләт йокысыннан уянып, изге айның хакын үтәп, барчабызга да аның күчтәнәчләрен, бүләкләрен күрергә насыйп булса иде.

***Гөлназ ГАЛИЕВА***

## БЕР СӨЕНӘМ, БЕР КӨЕНӘМ...

Раббыбызның рәхмәте чиксез киң Аның, менә тагын берничә көннән рамазан аена да аяк басабыз. Аллаһка шөкер, рамазанны бик олылыйлар хәзер, эссе җәй көннәренә туры килсә дә, ураза тотучылар бихисап күп. Элек Төркиядә рамазан ае буе халык төнлә дә урамда йөри, бер-берсен сыйлый, кунакка йөрешә, ай буе бәйрәм итә икән, дип сөйлиләр иде. Менә бит, Аллаһ рәхмәте, андый гадәтләр безнең Казаныбызга да килеп җитте. Мәчет яннарында чатырлар корып, мөселман кардәшләребез ай буе ифтар ашлары уздыралар. Җыелып тәравих намазыннан кайтып килүче яшьләрне күргәч, Йә Раббым, без дә шушы көннәрне күрдек, дим. Быел да уразаларыбызны тотып, гөнаһларыбыздан арынырга, бергә-бергә таравих намазларына йөреп, саваплар җыярга насыйп итсә иде.

Безнең татарда, бер мичкә балга бер кашык дегет салу, дигән әйтем бар, менә шул бер кашык дегет турында да әйтми булмый, җәмәгать. Ифтар ашларына, җаем туры килгәндә, мин үзем дә йөргәлим. Менә шунда бер бик күңелсез хәлне күреп, җаннарым әрнеп кайтам инде. Яшьләрнеке димим, бабайларныкы да түгел, ак яулыклы әбиләрнең тәртипләре ошап бетми миңа ул мәҗлесләрдә. Әле бөтен кеше тамак ялгарга өлгермәгән, алар инде әллә кайлардан гына пакетларын тартып чыгарып, табындагы ризыкны шунда тутыра да башлыйлар. Кайдан гына керде икән бу гадәтсезлек безнең халыкка? Анары кеше хакы дигән нәрсә дә бар бит әле. Ислам динен белгән, уразасын тоткан кеше ничек шуның гөнаһыннан курыкмый икән ул? Читтән карап торганда да бу - үтә дә ямьсез, күңелсез күренеш. Әбиләргә ничек итеп булса да менә шуны аңлатасы иде. Зинһар, мине дорфалыкта гаепли күрмәгез, халкыбызның бары тик күркәм якларын гына күрәсе килә бит, тоткан уразаларыбызның әҗер-савапларын җуймасак иде.

***Зәйтүнә РӘХИМҖАНОВА***

## УНБЕР АЙНЫҢ СОЛТАНЫ

Динебездә рамазан аен унике ай арасыннан аерып шулай дип атап йөртәләр. Иң беренче чиратта, шушы изге айда Аллаһының илчесе - пәйгамбәребез Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәләмгә Коръәни-Кәрим иңә башлавы белән кадерле ул безгә, икенчедән, рамазан аенда мөэминнәргә ураза фарыз ителде. Менә шушы айда Аллаһы Тәгалә каршында калебләребез зур сынау алдына куела. Кояш чыкканчы ук сәхәр ашап, кояш баегач кына сыйнигъмәтле табын янына утыру гына түгел бит әле ул ураза тоту, иң тәүдә без җаннарыбызның чисталыгын кайгыртырга бурычлы: колакларыбыз ярамаган сүз-гайбәт тыңламасын, телебез тиеш булмаганны такылдамасын, кулларыбыз хәрамгә үрелмәсен, аякларыбыз начар җиргә тартмасын, күзләребез хәерсез нәрсәләргә бакмасын, акылыбыз-йөрәгебез безләрне яңадан-яңа аятьләр, догалар өйрәнергә тартып торсын, калебебезнең һәрвакыт игелекләр генә кыласы килеп торсын! Менә шушыларны ихластан башкарып чыга алсак, уразабыз көне буена ач торуга гына кайтып калмас, иншә Аллаһ!

Ураза адәм баласын нәфесен кулда тотарга өйрәтә. Кеше бу айда Раббысы хакына үзенең яраткан нәрсәләреннән баш тарта, шуңа күрә аның әҗере дә зур. Бер китапта шундый мәгълүматка тап булдым. Галимнәр адәм баласының үз гомерендә никадәр ашый-эчә алуын исәпләп караганнар һәм шундый нәтиҗәгә килгәннәр: 10 мең литр су, 1000 кило май, 7000 кило ипи, 2000 кило ит, 4000 кило балык, 5000 кило бәрәңге, 5000 йомырка, 500 кило тоз кулланабыз икән яшәү дәверендә. Әле исемлеккә яшелчә, җиләк-җимеш, баллы ризыклар кертелмәгән. Булган хәтлесен дә төяп барыр өчен тулы бер поезд составы кирәк булыр иде, ди белгечләр. Бөтен гомеребезне ашап үткәрәбез икән, дияргә генә кала. Ә бит артыгын ашау күңелне каралта, тәнне авырайта, акылны йокыга тарта, кыскасы, һәм рухи, һәм бәдәни сәламәтлегебезгә зур зыян сала. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) тукланганда ашказанын өч өлешкә бүләргә киңәш итә: су, ризык, һава өчен. Шулай ук аның өйләнергә теләүче, әмма гаилә тормышын алып барырлык мая тупларга өлгермәгән ир-егетләр колагына шундый нәсыйхәте барлыгы да билгеле: андый очракта ул аларга ураза тотарга киңәш итә - яшь егетләрне зинадан саклау максаты күздә тотыла дип аңлыйм мин моны. Ислам галимнәре әгәр кеше тормышында ниндидер мөһим мәсьәлә килеп туса һәм ул аның чишелешен һич табалмый икән - нәфел уразасы тотарга киңәш итәләр. Хөрмәтле пәйгамбәребез (с.г.в.) исә атнага ике көн -дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә ураза тотуны хуплаган, үзе бер дә калдырмаган, безгә - аның сөннәтенә иярүчеләргә дә васыять иткән. Шулай итеп, уразаның җаннарыбызны тәрбияләүдә әһәмияте әйтеп бетергесез икән!

Кечкенә чагымнан бер күренеш истә калган. Ничектер йокымнан уянып киттем дә, караңгы өй эчен күзләргә тотындым. Әһә, бөтенләй үк караңгы түгел икән - бәләкәй якта ут яна. Кызыксынып, ишек ярыгыннан күз салам. Әбием белән бабам өстәл янында мәш киләләр. Менә бабам олы, җиз самавырны өстәл өстенә китереп утыртты, әбием чокырлар тезде, мендәр астыннан нидер алып, өстәлгә куйды. Тукта, әллә хәлвә инде?! Яратам бит мин аны! Сикереп тордым, киереп ишекләрне ачып җибәрдем, ә дигәнче әби белән бабай каршына килеп тә бастым:

- Миңа да хәлвә кирәк!

- И, кызым торган икән, хәзер бергәләп чәй эчәрбез, әбиеңнең яшереп саклаган хәлвәсе дә бар, - диде бабам миңа ярату тулы күзләре белән карап.

Ул иртәне мин карт белән карчыкның рамазан уразасын башлап җибәрүләрен белми идем әле. Әби белән бабай уртасында тәмләп чәй эчтем, алар, кулларын күтәреп, озаклап дога кылдылар, минем башымнан сыйпап алырга да онытмадылар. Шул кичне әни каенатасы белән каенанасына кичке ашны тагы да тәмлерәк, тагы да тырышыбрак пешерде. Бу - көне буена ашамый-эчми рамазан уразасын тоткан әбием белән бабама авыз ачу - ифтар ашы булган икән. Мин моны үсеп-җитеп, үзем иманга кайткач кына аңладым.

Ике коммунист, бер мулла (бабам) яшәгән гаиләдә тәрбияләнеп үскәнгә күрә, балачагымда дин турындагы хатирәләрем әлләни күп булмады. Шулай да бабамның йокларга ятар алдыннан учын каш өстенә куеп, озак кына күккә карап торганы да истә: яңа ай туганмыюкмы, шуны карый. Авыл мулласы буларак, аның халыкка мөһим хәбәр җиткерәсе булачак: фәлән көнне ай туды, җәмәгать, уразага керәбез... Еллар узгач, Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) хәдисен укып белдем: айны күреп керегез, айны күреп чыгыгыз, ди ул рамазан ае башлануын хәбәр итүче яңа ай хакында.

Менә тиздән, Аллаһым боерган булса, Җир шарындагы миллиард ярым мөселман белән беррәттән мин дә, хәләл җефетем дә чираттагы рамазан аена аяк басачакбыз. Унбер айның солтанын каршыларга бик ныгытып әзерләндек: фатир эчен юып-чистартып ялтыратып куйдык, тәрәзәләргә яңа челтәр пәрдәләр кордык һәм тагын шактый гына күңелле мәшәкатьләр белән мәшгуль булдык. Хуш киләсең, бәндәләрнең күңелләрен илаһи ният белән тутыручы изге Рамазан ае!

***Әкълимә САФИУЛЛИНА,***
***Казан***

# Төрмәдә Ураза тотучылар саны арта бара

**Тагын берничә көннән Изге рамазан аена аяк басабыз. Әлхәмдүлилләһи, сау-сәламәт булган кешегә ураза тотарга хәзер бөтен мөмкинлекләр бар: эш урыннарыбызда бернинди тыюлар, гаеп итешүләр юк, сәхәреңә-ифтарыңа җаңың ни тели - кибет-базар киштәләре хәләл ризыктан сыгылып тора. Күп кенә мәчетләр каршында хәтта ай дәвамында ураза тотучы мөселманнарга ифтар ашлары әзерләнә.**



*Рамазанны зарыгып көтүчеләр арасында ирекләреннән мәхрүм ителгән дин кардәшләребез дә шактый. Изге ай хөрмәтенә аларга нинди шартлар тудырыла икән? ТҖ МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт САБИРОВтан әнә шул хакта сораштык.*


- Диния нәзарәтенең колонияләрдәге мөселманнар белән эшләү тәҗрибәсе зур. Без Татарстандагы тугыз төрмә белән дә элемтәдә торабыз. Ә Изге рамазанда ифтар ашларын үткәрергә бер ай алдан әзерләнә башлыйбыз. Рәхмәт мөфти хәзрәткә, тоткыннарны ифтар ашларына хәләл ризык белән тәэмин итүне сорап язган хатыбызны ул берсүзсез имзалап чыгара. Бу сумма гына җитмәсә, кайбер мөселман кардәшләребез бик теләп ярдәм итә. Аннары инде рамазан кайчан башлана, ничәсенә кадәр дәвам итә, Гает бәйрәме кайчан була - шул хакта әйтеп, колониядә ифтар, Гает бәйрәме мәҗлесләрен үткәрергә, колонияләргә хәләл ризык кертергә рөхсәт сорап, Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә (УФСИН) хат язабыз. Әлхәмдүлилләһи, рөхсәт бирәләр, һәр колониягә хәләл ризык илтәбез, пешерүчеләргә дә шуннан ифтар ашлары әзерләргә әйтелә.

*- Ифтар ашлары намаз укыган, ураза тоткан тоткыннар өчен генә оештырыламы?*

- Юк, намаз укымаучы, ураза тотмаучы тоткыннар да килә ул мәҗлесләргә, аннары әкренләп уразасын тота башлый - безне менә шунысы бик сөендерә. Ифтар мәҗлесләрендә катнашканнан соң кайбер тоткыннар намазга да басалар, мәчеткә йөри башлыйлар. Рамазан ае - Аллаһның рәхмәте, бәрәкәте ае. Бу айда Аллаһ догаларыбызны кабул кыла, изге гамәлләр өчен савапларны арттырып бирә. Без моны колонияләрдә дә күрә алабыз. Кайбер тоткыннар нәкъ менә рамазан аенда дингә якыная, башка мөселман тоткыннардан күреп, сокланып, аларга иярә, намаз укымаучылар намазга баса, ураза тотмаучылар ураза тота башлый.

Ураза Гаете мәҗлесләрендә дә бик күп тоткыннар катнаша. Анда да намаз укымаучылар, ураза тотмаучылар күп була. Без аларны өстәл янына утыртып кунак итәбез. Күрсеннәр мөселман бәйрәмен, исламның матурлыгын, гүзәллеген! Ураза тоткан, ифтарларда катнашкан тоткыннарга да бу хакта әйтеп аңлатабыз, мәҗлесләребез үзенчә бер дәгъвәт булсын, башкаларны да чакырыгыз, дибез.

Бәйрәмнәребез бик матур уза, Аллага шөкер, без аларда үзебез дә катнашырга тырышабыз. Тоткыннар шушы Изге рамазан аен сагынып көтеп алалар. Узган ел ифтар мәҗлесләренә барлык колонияләрдән 500 дән артык кеше катнашты. Шунысын да әйтергә кирәк - ураза тотучыларның саны елдан-ел арта бара.



*- Апрель аенда Коръән укучылар арасында конкурс та уздырган идегез. Миңа калса, бу да колонияләрдә ислам динен тотучыларның арта баруына бер дәлил...*

- Әйе, бу конкурс быел дүртенче тапкыр уздырылды. Без аны Зөя утравында урнашкан 5 нче төзәтү колониясенең Әл-Фатиха мәчетендә үткәрдек. Андагы тоткыннар бик әзерлекле, гарәп телен, мәсәлән, мәдрәсә шәкертләре дәрәҗәсендә беләләр. Конкурста катнашкан 23 мөселман алты номинациядә көч сынашты. Әлбәттә инде, колониягә барып, аларга тәфсир, Коръән уку буенча дәресләр дә бирдек. Жюрида Россия ислам институты укытучысы Рөстәм Нургалиев, Диния нәзарәтеннән Айрат хәзрәт Зарипов, Марсель хәзрәт Мингалиев һәм Әл-Фатиха мәчете имамы үзе утырды. Тоткыннар арасыннан тамашачылар да күп иде. Җиңүчеләргә мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның Рәхмәт хаты белән бергә намаз вакытларын хәбәр итә торган сәгатьләр, электрон Коръән һәм һәр катнашучыга конкурс эмблемасы төшерелгән кружкалар тапшырылды. Соңыннан бергәләшеп мөфтият хисабына әзерләнгән чәй табынында сөйләшеп, фикер алышып утырдык. Бу да тоткыннар өчен зур вакыйга. Һәркемнең гөнаһларын танып, аларны кичерүен сорап, Раббысына мөрәҗәгать итәргә, туры юлны, хак динне табып, алдагы тормышын чиста кәгазьдән башларга мөмкинлеге бар. Ярлыкаучы - Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгалә, ә без мөселман кардәшләребезгә кулдан килгәнчә ярдәм итәргә бурычлы. Алга таба да менә шушы традицияләрне дәвам итәргә тырышырбыз, иншә Аллаһ.

***Әңгәмәдәш - Нәүбәһар КӘБИРОВА***






**Фотолар Дини нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге архивыннан алынды**

# "ХУЗУР"ДА ЯҢА КИТАПЛАР ДӨНЬЯ КҮРДЕ

**"Хузур" нәшрият йорты "Тәварихы Болгария" китабын нәшер итте. Рухи мирасыбызның бер ядкаре саналучы китапның авторы - дин белгече, мәгърифәтче Таҗеддин Ялчыгол (1768-1838). Шуны әйтергә кирәк, "Хузур" нәшрият йорты Ялчыгол иҗатына икенче мәртәбә мөрәҗәгать итә. Күптән түгел генә нәшриятта аның "Рисаләи Газизә" китабы басылып чыккан иде.**




Татарлар арасында популяр булган һәм үзенчәлекле фәнни фикерләр, бәхәсләр уяткан "Тәварихы Болгария"дә язылганнар бүгенге көндә дә үзенең мөһимлеген югалтмый. Шуны да әйтергә кирәк, бу әсәр хакында заманында Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин үз фикерләрен белдергән, шулай ук М. Госманов, Ә. Хәйри, М. Әхмәтҗанов кебек галимнәребез фәнни яктан тикшергәннәр.

1917 нче елга кадәр (1870-1902) "Тәварихы Болгария" китабы дүрт тапкыр басыла. Соңгы мәртәбә аны 1999 нчы елда мәрхүм Вәлиулла хәзрәт Якупов нәшер итә.

***

Күптән түген генә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан әзерләнгән, тикшерелгән беренче календарь - "Дини тәкъвим - 2015" тә дөнья күрде. Календарьны "Хузур" нәшрият йорты туплады һәм нәшер иттте. Әлеге календарь һәр көнебез ислам кыйммәтләре белән нурланып торсын, көндәлек тормышта мөселманнарга бер ярдәмлек булсын дигән нияттән тупланды.

"Дини тәкъвим" Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның вакыт хакында әйтелгән мөбарәк сүзләре белән ачыла: "Барча мөселманнарга вакытның тиз үтүен истә тоту, аны мәгънәле, дөрес итеп уздыру мөһим. Ислам дине вакытның кире кайтарып та, өстәп тә булмый торган бер аралык, үлчәм булуын искәртә. Көннәр, айлар, еллар үткәне сизелми дә диярлек, ә Кыямәт көнендә исә безнең җирдәге тормышыбыз, монда күргәннәребез бары бер мизгел булып тоелыр. Әгәр дә кеше вакытны Аллаһы Тәгаләнең бер кыйммәтле бүләге итеп кабул итсә, гомерен заяга үткәрмәсә, бу дөньяда да, ахирәттә дә уңышларга ирешүенә бер өмет булыр".




***Әлеге календарьны һәм "Хузур" нәшриятында чыккан башка китапларны сатып алырга теләүчеләр түбәндәге телефоннарга шалтыратып мөрәҗәгать итә ала: +7 (843) 202-07-74, 8-965-596-55-37. Нәшриятның сайты: huzur.ru***

# КАЗАН ТӘМЛЕТАМАКЛАРЫНА ГАРӘП КҮЧТӘНӘЧЕ

*BATEEL бутигы - хөрмәнең 20 сорты; шоколадлы, цукат һәм чикләвекле хөрмәләр; табигый шоколад; Италиядә җитештерелгән зәйтүн мае; Согуд Гарәбстаныннан китерелгән гарәп каһвәсе.*

*BATEEL, югары сыйфатлы хөрмә бренды булудан башлап, затлы азыктөлекләр базарында иң данлыклы маркага әверелде. Дөньяның уналты илендә уңыш казанган зиннәтле BATEEL бутиклары, кафелары Лондоннан алып Джакартага кадәрле бик күп мегаполисларның эре сәүдә үзәкләрен бизи.*

*BATEEL бутигында продуктларның искитмәле тәменнән башлап бизәк төшерелгән поднос рәвешендәге оформлениегә кадәр бар да купшы һәм кабатланмас - сатып алучылар үзләрен нәкъ көнчыгыш әкиятендәгедәй хис итәр.*

*Аллаһ Рәсүле (салләллаһу галәйһи вәссәлам) болай дигән: "Хөрмә оҗмах җимеше. Ул агуланудан дәвалау үзлегенә ия" (Тирмизи: Тыбб, 22).*

*BATEEL брендын чын тәмлетамаклар сайлый.*




# Казанда намаз вакытлары

| Милади 2014 ел | Көн исеме | Сәхәр тәмам | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Зәвәл | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы авыз ачу | Ястү намазы тәравих | Көн исеме | Һиҗри 1435 ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 27 | Җом | 02:00 | 02:30 | 04:00 | 12:46 | 13:00 | 18:34 | 21:32 | 23:02 | Пт | 29 | |
| 28 | Шим | 02:00 | 02:30 | 04:00 | 12:46 | 13:00 | 18:34 | 21:32 | 23:02 | Сб | 1 | РАМАЗАН |
| 29 | Якш | 02:01 | 02:31 | 04:01 | 12:46 | 13:00 | 18:34 | 21:31 | 23:01 | Вс | 2 | |
| 30 | Дүш | 02:02 | 02:32 | 04:02 | 12:47 | 13:00 | 18:34 | 21:31 | 23:01 | Пн | 3 | |
| 1 | Сиш | 02:03 | 02:33 | 04:03 | 12:47 | 13:00 | 18:34 | 21:31 | 23:01 | Вт | 4 | РАМАЗАН |
| 2 | Чәр | 02:03 | 02:33 | 04:03 | 12:47 | 13:00 | 18:34 | 21:30 | 23:00 | Ср | 5 | |
| 3 | Пән | 02:04 | 02:34 | 04:04 | 12:47 | 13:00 | 18:34 | 21:30 | 23:00 | Чт | 6 | |
| 4 | Җом | 02:05 | 02:35 | 04:05 | 12:47 | 13:00 | 18:33 | 21:29 | 22:59 | Пт | 7 | |
| 5 | Шим | 02:06 | 02:36 | 04:06 | 12:48 | 13:00 | 18:33 | 21:28 | 22:58 | Сб | 8 | |
| 6 | Якш | 02:07 | 02:37 | 04:07 | 12:48 | 13:00 | 18:33 | 21:28 | 22:58 | Вс | 9 | |
| 7 | Дүш | 02:08 | 02:38 | 04:08 | 12:48 | 13:00 | 18:33 | 21:27 | 22:57 | Пн | 10 | РАМАЗАН |
| 8 | Сиш | 02:09 | 02:39 | 04:09 | 12:48 | 13:00 | 18:32 | 21:26 | 22:56 | Вт | 11 | |
| 9 | Чәр | 02:11 | 02:41 | 04:11 | 12:48 | 13:00 | 18:32 | 21:25 | 22:55 | Ср | 12 | |
| 10 | Пән | 02:12 | 02:42 | 04:12 | 12:48 | 13:00 | 18:31 | 21:24 | 22:54 | Чт | 13 | |
| 11 | Җом | 02:13 | 02:43 | 04:13 | 12:49 | 13:00 | 18:31 | 21:23 | 22:53 | Пт | 14 | |
| 12 | Шим | 02:15 | 02:45 | 04:15 | 12:49 | 13:00 | 18:30 | 21:22 | 22:52 | Сб | 15 | РАМАЗАН |
| 13 | Якш | 02:16 | 02:46 | 04:16 | 12:49 | 13:00 | 18:30 | 21:21 | 22:51 | Вс | 16 | |
| 14 | Дүш | 02:17 | 02:47 | 04:17 | 12:49 | 13:00 | 18:29 | 21:20 | 22:50 | Пн | 17 | |
| 15 | Сиш | 02:19 | 02:49 | 04:19 | 12:49 | 13:00 | 18:29 | 21:18 | 22:48 | Вт | 18 | |
| 16 | Чәр | 02:20 | 02:50 | 04:20 | 12:49 | 13:00 | 18:28 | 21:17 | 22:47 | Ср | 19 | |
| 17 | Пән | 02:22 | 02:52 | 04:22 | 12:49 | 13:00 | 18:27 | 21:16 | 22:46 | Чт | 20 | |
| 18 | Җом | 02:23 | 02:53 | 04:23 | 12:49 | 13:00 | 18:27 | 21:14 | 22:44 | Пт | 21 | РАМАЗАН |
| 19 | Шим | 02:25 | 02:55 | 04:25 | 12:49 | 13:00 | 18:26 | 21:13 | 22:43 | Сб | 22 | |
| 20 | Якш | 02:26 | 02:56 | 04:26 | 12:49 | 13:00 | 18:25 | 21:11 | 22:41 | Вс | 23 | |
| 21 | Дүш | 02:28 | 02:58 | 04:28 | 12:49 | 13:00 | 18:24 | 21:10 | 22:40 | Пн | 24 | |
| 22 | Сиш | 02:30 | 03:00 | 04:30 | 12:49 | 13:00 | 18:24 | 21:08 | 22:38 | Вт | 25 | |
| 23 | Чәр | 02:31 | 03:01 | 04:31 | 12:50 | 13:00 | 18:23 | 21:07 | 22:37 | Ср | 26 | РАМАЗАН |
| 24 | Пән | 02:33 | 03:03 | 04:33 | 12:50 | 13:00 | 18:22 | 21:05 | 22:35 | Чт | 27 | |
| 25 | Җом | 02:35 | 03:05 | 04:35 | 12:50 | 13:00 | 18:21 | 21:03 | 22:33 | Пт | 28 | |
| 26 | Шим | 02:36 | 03:06 | 04:36 | 12:50 | 13:00 | 18:20 | 21:01 | 22:31 | Сб | 29 | |
| 27 | Якш | 02:38 | 03:08 | 04:38 | 12:50 | 13:00 | 18:19 | 21:00 | 22:30 | Вс | 30 | |
| 28 | Дүш | 02:40 | 03:10 | 04:40 | 12:50 | 13:00 | 18:18 | 20:58 | 22:28 | Пн | 1 | ШӘҮВӘЛ |
| 29 | Сиш | 02:42 | 03:12 | 04:42 | 12:50 | 13:00 | 18:17 | 20:56 | 22:26 | Вт | 2 | |
| 30 | Чәр | 02:44 | 03:14 | 04:44 | 12:49 | 13:00 | 18:16 | 20:54 | 22:24 | Ср | 3 | |
| 31 | Пән | 02:45 | 03:15 | 04:45 | 12:49 | 13:00 | 18:15 | 20:52 | 22:22 | Чт | 4 | |
| ДАТА | ДЕНЬ НЕДЕЛИ | ОКОНЧАНИЕ СУХУРА | ФАДЖР | ВОСХОД СОЛНЦА | ЗЕНИТ | ЗУХР | АСР | МАГРИБ ИФТАР | ИША ТАРАВИХ | ДЕНЬ НЕДЕЛИ | ПО ХИДЖРЕ | |

# МӘЧЕТ ТӨЗЕЛЕШЕНӘ ЯРДӘМ КИРӘК



## *Хөрмәтле мөселман кардәшләребез!*

Мәчетебезне төзеп бетерүдә ярдәм күрсәтүегезне сорап, сезгә Әмәт бистәсе мөселманнары исеменнән мөрәҗәгать итәбез.

**БЕЗНЕҢ РЕКВИЗИТЛАР:**

***Приход п. Ометьево Казанского Мухтасибата***
***р/с 40703810100000000303***
***ИНН 1655064078***
***КПП 165501001***
***Банк реквизитлары (ОАО АИКБ "Татфондбанк", Казан шәһ.)***
***БИК: 049205815***
***К/счёт 30101810100000000815 в ГРКЦ НБ РТ***

**Мәчет имамының телефон номеры: 89297288860**

ДИН вә Мәгыйшәт

**Гамәлгә куючы: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте** *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27) .*
**Нәшир: "Хузур" нәшрият йорты** *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в).*

**Июнь саны, № 6 (227)**

**Баш мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ
**Мөхәррир:** Нәүбәһар КӘБИРОВА
**Дизайнер:** Гүзәл МИҢНУЛЛИНА
**Корректор:** Айгөл КРОХИНА
Газета логотибы **хәттат** Рамил НАСЫЙБУЛЛОВ тарафыннан эшләнде

**Редакция советы:**
*Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе* ***Камил СӘМИГУЛЛИН;***
*"Хузур" нәшрият йорты директоры* ***Ришат ХӘМИДУЛЛИН;***
*Татарстан мөфтие урынбасары* ***Нияз САБИРОВ;***
*Татарстанның баш казые* ***Җәлил ФАЗЛЫЕВ;***
*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе* ***Габдулла ӘДҺӘМОВ.***

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).
Заказ № 09612
**Тираж: 10 мең данә**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя – 6 сум.
График буенча бу санга **21 нче апрель көнне 18.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде. **Кул куелды: 18.00 сәгатьтә.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Электрон адрес: niyaz-kazan@yandex.ru**
**Телефон:** +7 (843) 267-29-67.

**Язылу индексы: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин.**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**